ХАТ ЭЗЕННӘН

Агрофирмада хезмәт хаклары ник аз?

> 6

ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ

Тукай җырларында җырланган Зәйтүнә кем ул?

> 16

РАВИЛ САБЫР:

«Сталин премиясенә бүген 16 япон машинасы алып булыр иде»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 49 (28822) | Җомга | 8 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

pixabay.com

АЧЫК КАПКА

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Ничек кенә тырышсак та, шәхси мәгълүматны җиде йозак астында бикләп тотып булмый. Мәгълүмат белән уртаклашу һәм аның ниндидер сәбәпләр аркасында башкалар кулына килеп эләгүе даими рәвештә күзәтелә. Гаҗәпләнәсе дә түгел: кибеттә кием-салым, азык-төлек өчен карта белән түләгәндә дә, ниндидер бәйгедә катнашканда анкета тутырганда да, социаль челтәрләрдә дә бара ул. Тормышыбызның бер өлешенә әверелгәнгә күрә, моны сизмибез, игътибар итмибез генә. Көннәрдән бер көнне көймәбез комга терәлгәнче...

> 5

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча, социаль түләүләр һәм пенсияләр күләме арттырылачак. Премьер-министр Михаил Мишустин сүзләренә караганда, хезмәт хакын һәм яшәү минимумы күләмен үстерү дә күздә тотыла. Исегезгә төшерәбез: дәүләт башлыгы инде март башында ук пенсияләр һәм социаль пособиеләрне индексацияләүне планлаштыру турында белдергән иде.

Узган елда Татарстанда аерылышу очраклары күп булган. Барлыгы 14876 никах таркалган. Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина аңлатып үткәнчә, бу, 2020 елда коронавирус пандемиясе таралу сәбәпле, кавышу-аерылышуларны теркәү эшчәнлегенең туктатып торылуына гына бәйле. «Алдагы еллардагы статистика белән чагыштырганда, таркалган никахларның гомуми саны бер үк дәрәҗәдә диярлек кала», – дигән ул. Республикада, әйтик, 2018 елда – 13456, 2019 елда 13316 гаилә пары аерылышкан. 1000 никахка барлыгы 603 аерылышу туры килә.

Мәскәү – Казан М12 яңа автомобиль юлының тәүге өлешләре агымдагы ел ахырына кадәр ачылачак. «Барлыгы 1,6 мең чакрымнан артыграк озынлыктагы «Көнчыгыш – Көнбатыш» проектын гамәлгә ашыру башланды. Бу ике магистраль төзүне һәм Мәскәү – Казан юлының беренче участокларын этаплап ачу мөмкинлеген аңлата, – диде Премьер-министр Михаил Мишустин Дәүләт Думасында. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта М12 юлын Екатеринбургка кадәр дәвам итү проекты эшләнә. Юлның бу өлешен төзү дә инде быел ук башланачак. Түләүле яңа юл, Казанны урап, аэропорт тирәсендә урнашкан логистика үзәкләренә барып тоташачак. Ул шулай ук Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узачак.

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**, гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**, гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

БАРЫСЫ ДА БЕР УРЫНДА

Казанда туберкулезга каршы диспансерның яңа бинасы ачылды. Моңа кадәр әлеге чиргә каршы көрәш башкалада берничә урында алып барыла иде. Хәзер исә табибларны бер түбә астына җыйдылар. Яңа диспансер белгечләре халыкны дүшәмбедән кабул итә башлаячак.

Башкасына да яңа кирәк

Казанның Җиңү проспекты 69б адресы буенча урнашкан яңа диспансер 9,5 мең квадрат метр мәйданлы биш катлы яңа бинадан гыйбарәт. Аны ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. «Бу проектка 1 миллиард 165 миллион сум акча сарыф ителде. Диспансер көненә 680 кешене кабул итәргә сәләтле. Моңа кадәр шәһәр буйлап сибелгән объектлар хәзер бер түбә астында урнашачак», – диде Президент үз чыгышында. Казандагы яңа диспансер ачылышында видеоэлемтә аша Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Татьяна Голикова белән илнең сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко да катнашты.

Голикова сүзләренә караганда, соңгы өч елда Россиядә туберкулез белән авыручылар саны – 24,5, аннан үлүчеләр саны 19,6 процентка кимегән. Ә Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков китергән саннардан аңлашылганча, соңгы ике елда республикада туберкулез йоктыру очраклары – 18,8, аннан үлүчеләр саны 28 процентка кимегән. Министр сүзләренә караганда, туберкулезга каршы диспансерның элеккеге биналары да буш калмаячак. Әйтик, Шаляпин урамындагы 1905 елда ук төзелгән бинаны сүтеп, аның урынында республика офтальмология хастаханәсе яки тире-венерология диспансеры барлыкка киләчәк. «Бу урында төгәл нәрсә төзеләчәге республика җитәкчелеге белән бергә хәл ителәчәк. Кызганыч, соңгы елларда барлык махсус хезмәтләр, онкологиядән тыш, иске биналарда урнашкан. Акрынлап аларны яңартачакбыз», – дип ышандырды министр.

tatarstan.ru

Йогар дип куркасы юк

Дүшәмбедән тулы куәткә эшли башлаячак яңа диспансерда белгечләр көненә ким дигәндә 680 кеше кабул итә алачак, дип ышандыралар. Шуларның 420се – зурлар, калганы – балалар. Шушы бер бинада кеше бер көндә бөтен кирәкле анализларын да тапшыра, тикшеренү уза, компьютер томографиясе ясатып, кирәкле табибларны да йөреп чыгарга өлгерәчәк. Әмма бу туберкулез белән авырган кеше белән бер белешмә артыннан килгән сау-сәламәт кеше бөтенесе бер урында кайнаячак дигән сүз түгел. Диспансерда аларның юлы беркайчан да кисешмәячәк дип ышандыралар: алар төрле ишекләрдән керәчәк, аларны төрле бүлекләрдә кабул итәчәкләр.

Туберкулезга каршы диспансерның баш табибы Алексей Алексеев сүзләренә караганда, барлык хезмәтләрнең бер түбә астында урнашуы туберкулез авыруын вакытында ачыклап, чирне тиз арада дәвалап, җиңәргә ярдәм итәчәк. Яшерен-батырын түгел, шушы диагнозны ишетүгә кеше шок хәлендә кала, төшенкелеккә бирелә, кеше янына бөтенләй чыкмас була. «Андыйларның күбесе еш кына диагнозын ахыргача ачыклап та бетермичә юкка чыга. Яңа диспансер әнә шундый очракларны да кисәтер дип өметләнәбез. Бездә психологик ярдәм күрсәтү дә каралган», – ди баш табиб.

Диспансердагы 46 табиб-фтизиатр, 7 тар белгеч (уролог, гинеколог, ортопед, офтальмолог, хирург, пульмонолог, отоларинголог) кабул итәчәк. Яңа диспансерда кулланылачак җиһазларның 80 проценты үзебездә җитештерелгән. Аларны сатып алу өчен 110 миллион сум акча сарыф иткәннәр.

Диспансерның баш табибы шәһәр эчендә урнашкан бинадан шикләнүчеләрне дә тынычландырырга ашыкты. Ник дигәндә, туберкулез – һава юлы белән күчә торган йогышлы авыру. Шуңа күрә Идел буе районында туберкулезга каршы диспансерның яңа бинасы төзеләчәген ишеткәч, үл тирәдә яшәүчеләр, безгә куркыныч янамыймы, дип борчылды. «Диспансердагы бүлмәләр көчле вентиляция һәм зарарсызландыру системасы белән җиһазландырылган. Шуңа күрә безнең бинадан урамга фәкать чиста һава гына чыга», – дип ышандырды Алексей Алексеев.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАРАП ТОРАЛАР

Узган ел Татарстанда күзәтү камералары ярдәмендә 1787 җинаять фаш ителгән. Файдасы бар, шуңа күрә республикада «Имин шәһәр» комплексын алга таба да үстерергә ниятлиләр. Бу хакта Хөкүмәт йортында Иминлек Советы һәм Хокук тәртибен тәэмин итү буенча координацион киңәшмәнең Президент Рөстәм Миңнеханов уздырган уртак утырышында сөйләштеләр.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, «Имин» шәһәр комплексы җинаятьчелекне киметергә һәм хокук тәртибен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Хокук саклау органнары тиз арада кирәк мәгълүматны ала, кирәк икән, аны тикшерү барышында куллана. Президент фикеренчә, «Имин шәһәр» проектын тормышка ашырганда заманча чаралардан файдаланырга һәм иң яхшы нәтиҗәгә ирешергә кирәк.

Татарстанның мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин хәбәр иткәнчә, хәзерге вакытта республикада 67 меңнән артык видеокамера эшли. Тулаем алганда, 2016 елдан «Имин шәһәр»не булдыру һәм үстерү өчен 2,3 млрд сум акча тотылган. 2021 елда заманча алымнар кулланып, бюджет чыгымнарын 3 тапкыр киметә алганнар. Әйтик, былтыр 132 млн сум акча тотылган. Хәзер бер камераның чыгымы 7 меңнән 5 мең сумга калган.

Проектны исә 5 юнәлеш буенча тормышка ашыралар. Камераларны җәмәгать урыннарында (урамнар, парклар, скверлар), күпфатирлы торак йортларда, транспорт инфраструктурасы корылмаларында (тимер юл һәм автовокзаллар, күперләр, зур юл чатлары), социаль объектларда (мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт һәм мәдәният оешмалары), кибетләр һәм сәүдә үзәкләрендә урнаштыралар.

Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин билгеләп үткәнчә, 2022 елның 3 аенда гына да камералар ярдәмендә 502 җинаять ачылган һәм 1745 хокук бозу очрагын булдырмый калганнар. Министр әйтүенчә, видеокүзәтү системасының кирәклегенә алар һәр көнне ышана. Инде тагын да файдалырак булсын өчен Артем Хохорин яңалыклар кертергә, әйтик, техник чараларга тулы ревизия ясарга, бердәм видеокүзәтү платформасы төзергә, «акыллы» домофоннар санын арттырырга, район һәм шәһәрләрдә эш төркемнәре булдырырга, архивта саклanучы видеоязмаларны карау тәртибен яңартырга тәкъдим итә.

Президент фикеренчә, видеокүзәтү системасы – иминлекне тәэмин итү буенча иң нәтиҗәле корал. «Бүген бу система халыкка балаларны тыныч күңел белән урамга чыгарып җибәрергә, үзләренә тынычлап йөрергә мөмкинлек бирә. Камералар ярдәмендә 1,7 меңнән артык җинаять ачылган. Камералар булу һәм тиз арада чарасын күрү мөмкинлегә явыз ниятле кешеләрне дә туктатып кала», – диде ул. Рөстәм Миңнеханов булган камераларны тикшереп чыгарга һәм 2025 елга кадәр «Имин шәһәр» комплексын үстерү концепциясен әзерләргә кушты.

КАЙГЫ УРТАКЛАШТЫЛАР

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, ЛДПР башлыгы Владимир Жириновский вафат булу сәбәпле, аның якыннарының һәм партия вәкилләренең кайгысын уртаклашты. Телеграмма Дәүләт Думасының Халыкара эшләр буенча комитеты рәисе Леонид Слуцкийга юлланган. Ул вакытлыча фракция җитәкчесе вазыйфаларын башкара.

«Владимир Вольфович Жириновскийның – илнең яңарышына һәм төрле яклап үсешенә зур өлеш керткән тәҗрибәле сәясәтче, энергияле парламентарий, Россиянең чын патриоты вафат булуын тирән кайгы белән кабул иттем. Аны белгән һәм хөрмәт иткән һәркем үзенчәлекле, көчле бу кеше турында якты истәлек саклар дип ышанам. Мәрхүмнең туганнарының һәм якыннарының, аның партиядәшләренең кайгыларын, Сезнең кайгыгызны уртаклашам», – диелә телеграммада.

Кайгы уртаклашу телеграммасын Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да юллады. «Һәрвакыт иҗтимагый тормышның үзәгендә була торып, ул хезмәттәшләре арасында абруй казанды һәм сайлаучыларның теләктәшлеген тойды», – дигән республика парламенты җитәкчесе. Фәрит Мөхәммәтшин Владимир Жириновскийның заманча Россия дәүләтчелеген торгызуга, Россиянең милли мәнфәгатьләрен яклауга зур шәхси өлеш кертүен әйткән.

ЯҢА СЕЗОННЫ БАШЛАДЫЛАР

Казанда «Авторетроклуб-21» тарихи техника сөючеләр клубының гомуми утырышы үткәрелде. Борынгы автомобильләргә мөкиббән китүчеләр анда узган елга йомгак ясап, яңа сезонга планнары белән уртаклашты. Моннан тыш клуб әгъзалары идарә составын яңартты, кайбер оештыру мәсьәләләрен хәл итте. «Авторетроклуб-21» президенты итеп янә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сайланды.

Дәүләт Советы Рәисе, утырышны ачып, узган елның гади генә булмавын, әмма, пандемиягә карамастан, билгеләнгән планнарның тормышка ашырылуын билгеләп үтте. Парламент башлыгы шулай ук автомобиль төзү тарихына сакчыл мөнәсәбәтләре һәм урыннарда, районнарда зур иҗтимагый, агарту эше алып барулары өчен клуб активистларына рәхмәт белдерде.

«Авторетроклуб-21» идарәсе рәисе Айдар Ибәтуллин узган елгы эш йомгаклары белән таныштырып үтте. Клуб әгъзалары 9 Майда Җиңү парадында, 13–15 августта «Свияжские холмы» тау чаңгысы комплексында уңдүртенче тапкыр уздырылган халыкара тарихи техника фестивалендә катнашкан. Клуб активистлары шулай ук, автомобиль тарихын өйрәнүне популярлаштыру максатыннан, мәктәп укучылары һәм борынгы техникага мөкиббән китүчеләр өчен лекцияләр үткәргән.

Быелга корылган планнарга килгәндә, Айдар Ибәтуллин башка шәһәрләрдәге коллегалары белән хезмәттәшлекнең елдан-ел ныгуын басым ясап әйтте. Быел клуб әгъзалары Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 77 ел тулуга багышланган парадта катнашырга ниятли. Шулай ук май аенда Татарстанның тарихи урыннары буйлап сәяхәт уздырырга җыеналар. Декабрьдә «Кышкы ретро-кросс» үткәрү күздә тотыла. Моннан тыш клуб әгъзалары Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган кайбер чараларда да катнашырга ниятли.

Җыелышта халыкара тарихи техниканың юбилей – 15 нче фестивален үткәрү көне дә мәгълүм булды. Әлеге вакыйга «Свияжские холмы» тау чаңгысы комплексында 12–14 августта үткәреләчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанның Җиңү паркындагы хәрби-интернационалистлар һәйкәле янына йөзләрчә кеше җыелды. Биредә Россия Кораллы Көчләрен һәм Донбасста яшәүчеләрне хуплау йөзеннән митинг-концерт узды. Чара Донецк Халык Республикасы оештырылуга 8 ел тулуга багышланды. «Бирегә килүебезнең сәбәбе – Донбасстагы хәлләргә битараф калмау. Без анда яшәүче халык өчен нык борчылабыз һәм аларга төрле яклап ярдәм итәчәкбез. Донбасстан Казанга бик күп кешеләрнең килүен беләбез, без аларга ярдәм итәргә әзер», – ди Россия армиясенә теләктәшлек белдерергә килүчеләр. Чарада ветераннар, иҗтимагый оешмалар, сәяси партияләр һәм хәрәкәт вәкилләре катнашты. Ватанпәрвәрлек акциясенә җыелучылар алдында сәнгать әһелләре чыгыш ясады.

КЫРЫМГА БАРЫП ҖИТТЕ

Премьер-министр урынбасары – Татарстанның Россиядәге вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин җитәкчелегендә республика делегациясе Кырымга Донецк һәм Луганск халык республикаларында яшәүчеләр өчен 20 тоннадан артыграк гуманитар ярдәмне китереп җиткерде. Гуманитар йөкне, Россия Кораллы Көчләре Генераль штабы ярдәмендә, Оборона министрлыгы самолетында алып барганнар.

Ярдәм, мохтаҗларга өләшү өчен, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләренә тапшырылган. Асылда азык-төлектән һәм беренче чиратта кирәкле товарлардан торган гуманитар ярдәм өч шәһәрдә – Казан, Чаллы һәм Әлмәттә җыелган.

Исегезгә төшерәбез: Равил Әхмәтшин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе 23–24 мартта Севастопольгә 65 тонна гуманитар йөк илтеп тапшырган иде инде. Ул чагында ярдәмне өч район – Актаныш, Алексеевск һәм Тәтеш җыеп бирде. Ул вакытта да йөкне Оборона министрлыгы авиациясе алып барып җиткерде.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Ярдәм вәгъдә итәләр

Татарстанда импорт алмаштыру үзәге эшли башлады. Санкцияләр чорында республика хөкүмәте тарафыннан эшмәкәрләргә ярдәм йөзеннән кабул ителгән чараларның берсе әнә шуннан гыйбарәт. Бу хакта журналистларга Татарстан икътисад министрының беренче урынбасары Рөстәм Сибгатуллин хәбәр итте.

Ул сөйләгәннәрдән аңлашылганча, яңа үзәк үзебезнең эшмәкәрләр тарафыннан җитештерелгән товарлар тупланган каталогны хәтерләтә. Анда теләге булган һәр эшмәкәр үзе җитештергән товарны урнаштыра ала. «Ул ике өлештән тора: сул якта моңа кадәр сатып алынган импорт продукциясе урнаштырылган. Андагы әйберләр саны 100 меңнән арта. Уң якта исә аларны алмаштыра алырлык үзебездә җитештерелгән товарлар урын алган. Аларның саны 109 меңнән арта», – дип ачыклык кертте Сибгатуллин.

Министр урынбасары килеп туган вазгыятьтә эшмәкәрләргә үз товарларын маркетплейслар аша да сатарга киңәш итә. «Хәзерге вакытта иң нәтиҗәле ысулларның берсе бу. Электрон форматтагы базар соңгы арада бик нык үсте. Мондагы әйберләрне ил күләмендә сатып алалар. Анда «киштә»гә куеп булган товарлар саны да чикләнмәгән, эшмәкәрнең чыгымнары да азрак. Аннары маркетплейска әләгү гадәти базар киштәсендә урнашуга караганда күпкә җиңелрәк», – ди Рөстәм Сибгатуллин.

Быел республикада кече һәм урта эшмәкәрлек тармакларына ярдәм йөзеннән 4,5 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Әлеге тармак вәкилләре белән очрашканнан соң, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шундый карар кабул иткән.

Моннан тыш Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды 7 яңа микрофинанс программасын да эшләтеп җибәрәчәк. Аның кысаларында эшмәкәрләр ташламалы кредит ала алачак. Әлеге кредитларның процент ставкасы Үзәк банкның элеккеге төп ставкасы чамасында – 13,5 процентка кадәр булачак дип ышандыралар. Билгеле булганча, март башыннан Үзәк банк төп ставканы 20 процентка кадәр күтәрде. Яңа программалардан файдалану өчен гаризалар 6 апрельдән кабул ителә башлаган. Моның өчен үзмәшгульләр Эшмәкәрлеккә ярдәм фондының төбәк бүлегенә яки күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Калган эшмәкәрләр исә гаризаны фасттрек.рф порталы аша тапшыра ала.

Алда телгә алган ярдәм чараларыннан тыш фонд эшмәкәрләргә элегрәк алган кредитлар буенча түләүләрне 18 айга кадәр кичектереп торырга да рөхсәт итмәкче. Яшь эшмәкәрләргә грантлар да вәгъдә итәләр.

8–17 ЯШЬЛЕК БАЛАСЫ БУЛГАН ГАИЛӘЛӘР ЯҢА ПОСОБИЕ АЛУГА ГАРИЗАНЫ 1 МАЙДАН ТАПШЫРА БАШЛАЯЧАК

8–17 яшьлек баласы булган аз керемле гаиләләргә яңа пособие бирү буенча гаризны кабул итү 1 майда башлана. Шул ук вакытта пособие инде апрельдән үк билгеләнәчәк. Ягъни 1 майдан соң гариза тапшыручыларга берьюлы ике айга – апрель һәм майга акча биреләчәк. Дөрес, балага апрель аенда 8 яшь тулган булырга тиеш. Пособие алуның төп шарты – гаилә кеременең аз булуы. Яңа түләү җан башына туры килә торган керем төбәктә бер кешегә яшәү минимумы күләменнән кимрәк гаиләләргә билгеләнәчәк.

Яңа түләүнең күләме дә керемгә бәйле. Төбәктә бала өчен яшәү минимумының 50, 75 яки 100 процентын тәшкил итәргә мөмкин ул. Пособиенең төп күләме – 50%, ил буенча уртача 6150 сум дигән сүз бу. Шулай түләп тә, гаилә кереме барыбер бер кешегә яшәү минимумыннан кимрәк булып чыкса, пособие балага яшәү минимумының 75 проценты күләмендә билгеләнәчәк. Инде болай да гаиләнең җан башына туры килә торган кереме яшәү минимумыннан кимрәк икән, яшәү минимумының 100 проценты дәрәҗәсендә пособие биреләчәк.

Исегезгә төшерәбез: әлегә фәкать ялгыз ана яки ялгыз аталар гына 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалары өчен пособие алырга мөмкин. Аның күләме төбәктә бала өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменең 50 процентын тәшкил итә.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Акылдан шашу

Ишегалдында күптән күренмәгән күршемне очраттым. Шактый вакыт авырып яткан икән. Дөресен генә әйткәндә, аның күзенә бик чалынмаска тырышам, чөнки килде-китте сораулар биреп тинтерәтергә ярата ул. Бу юлы да: «Эшләр барамы, Украинадагы хәлләр турында язасыңмы?» – дип сүз башлады.

– Юк, – мәйтәм.

– Нигә?

– Чөнки анда булганым юк.

– Булмасаң, телевизор карыйсыңдыр бит?

– Мин үзем күргән-белгәнне генә язам.

– Хохоллар бик бирешми, име?

Аның миннән бер-бер сүз ишетәсе килә иде, ә мин дәшмим.

– Кайчан бетәр икән бу операция дигәннәре?

– Сиңа нәрсәгә соң ул?

– Ник... кызык ич.

Күршем фаҗигадән нинди кызык табадыр – белмим.

Россия телеканалларыннан Украинадагы хәлләр турында тәүлек буе тапшырулар бара һәм шәхсән үзем аларны карамаска тырышам.

Беркөнне интернетта гыйбрәтле генә санга тап булдым. Дөнья йөзләрендә һәр биш кешенең берсендә психик тайпылыш бар икән. Бу – Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы биргән сан. Әле психика бозылуның дөньядагы иң популяр биш авыру исемлегенә керүен дә язганнар. Бу хезмәтнең төп билгеләре, гади генә әйткәндә, кешенең үз-үзен тотышы, фикерләү рәвеше үзгәрү, башында гайре табигый уйлар туу, агрессия йә, киресенчә, төшенкелеккә бирелү булу инде. Соңгы елларда дөньяда «психлар» саны 13 процентка арткан дигән мәгълүматка да тап булдым. Мин табиб-психолог түгел, шуңа күрә әлеге авыруның килеп чыгу сәбәпләре, дәвалау ысуллары турында яза алмыйм. Мине бер нәрсә борчый: кайвакыт, үзебез теләп, психка әйләнмибез микән? Мәсәлән, Украинадагы вакыйгалар турында тулы мәгълүмат булмау кайберәүләрне чыгырыннан чыгара.

Кайберәүләр: «Нигәдер үлүчеләр саны бик аз», – дип борчылып, тәмам күңел тынычлыгын югалта. Андыйлар үземнең таныш-белеш арасында да шактый очрый. Мин аларга: «Нәрсә эшләргә кирәген җитәкчелек белә, үзеңне бетермә!» – дип әйтеп карыйм, әмма танышлар минем белән бәхәсләшә, хәтта талаша башлыйлар, берсеннән-берсе куркыныч хәлләр турында уйдырмалар, имеш-мимешләр сөйлиләр.

Беркөнне шул ук күршем бик белдекле кыяфәт белән бер танышының үз машинасында кирәк-ярак тутырылган юл капчыгы йөртүе турында сөйләде. Тегe танышы элекке «гаишник» икән һәм мобилизация игълан иткәннәрен көтеп яши, ди. «Любой вакытта повестка китерергә мөмкинләр, шуңа күрә запас кием-салым тутырган сумка гел машинада йөри», – дип әйткән, имеш. «Ниткән танышың соң ул?» – дип сораган идем, ул бер танышының танышы булып чыкты.

Олы ялган кече ялганнардан башлана. Без ни өчен күңелсезлекләрдән дә кызык эзлибез соң? Кызык таба алмасак, нигә бәргәләнә башлыйбыз икән? Моңа баш җитми. Әллә бөтен дөнья акылдан шашамы, дип тә уйлап куям. Мондый тайпылышлар табигатьтәге, җәмгыятьтәге тетрәнүләр, тотрыксызлыкка бәйледер, дип әйтәсе килә үзе. Алай булса, демократия чәчәк аткан, иң бай ил саналган Америкада ни өчен һәр дүрт кешенең берсе психологка мөрәҗәгать итә икән? Әле аның мөрәҗәгать итмәгәннәре дә шактыйдыр. Аптыраганнан әйтү инде, калганын үзегез уйлап бетерегез!

Шушы язмамны тәмамладым да, эшкә барырга дип, ишегалдындагы машинам янына чыктым. Карасам, тегe күршем килә. Авызы ерык. «Нихәл, Украина турында берәр нәрсә яздыңмы?» – ди.

– Юк. Борчылма син, үзеңне бетермә! Күңелсезлекләр үтә дә китә ул. Тормыш начар түгел бит! – дидем дә кузгалып киттем. Аның: «Синдә генә инде яхшы тормыш...» – дип сөйләнгәннәре генә колакка чалынып калды. Бераз кызганып та куйдым үзен, миннән үзе теләгәннәрне ишетә алмады бит, җүнләп йоклый да алмас бүген. «Вәт, псих!» – димәкче идем дә, туктап калдым. Авыру кешене рәнҗетү килешмәс дидем.

ҺӘРВАКЫТ БОЛАЙ БУЛМАС

Мин тормыштагы кыенлыкларны җиңәргә өйрәтә торган гыйбрәтле хикәяләр җыярга яратам. Беләсезме: яшәештә бит иң кыйммәтле нәрсә – валюта запасы да түгел, кара көнгә дип тупланган азык-төлек күләме дә түгел, ә тәҗрибә. Тегe хикәятләр безгә тәҗрибәне бушлай бирәләр.

Хәзерге көн өчен әһәмиятле бер хикәятне искә төшерик. Бер бик фәкыйрь күпбалалы гаилә яшәгән. Тормыш авыр чакта иң әһәмиятлесе бит – күңелне төшермәү, икенче төрле әйткәндә, мотивацияң булу. Төшенкелек һәлакәткә илтә, мотивация исә гел алга өнди. Ашкынып, елларны узуыңны сизми дә каласың, күпме дәвам итсә дә, авырлыкларга бирешмисең. Тегe гаилә турында сөйли башлаган идем бит. Шуларның тормышлары озакка сузылган авырлыклар чылбырыннан торган. Әти кеше, балаларны өметләндерү өчен, стенага: «Һәрвакытта да болай булмас», – дигән язу элеп куйган. Шул язуга карыйлар да тормышны алга этәргә тырышалар икән. Күбрәк әти тырыша инде, чөнки балалар кечкенә. Акрынлап шулай фәкыйрьлектә еллар узган. Балалар үскән. Шулай да көннәрдән бер көнне гаиләгә мохтаҗлык базыннан күтәрелеп, муллыкка ирешү насыйп булган. Яхшы итеп йорт җиткергәннәр, ашау-эчү затлыга һәм мулга әйләнгән, кием-салым да яхшы. Яңа өйнең диварына әти кеше тагын шул язуны элеп куйган: һәрвакытта да болай булмас. Инде үсеп буй җиткергән, егет булып килгән улларының берсе: «Әти, авыр чаклар артта калды бит инде, бу язуны алып ташлыйк», – дигән. «Торсын, улым, – дигән әтисе, – чөнки һәрвакытта да болай булмас».

Россиянең бүгенге хәле шул хикәяттәге төсле. Бердән, углеводородлар акчасы мул булып яуган елларда без үзебезне мәңгелек байлыкка ирешкән кебек тоттык: бар нәрсәне читтән сатып алып, икътисадны кирәгеннән артык глобаль икътисадка бәйләп куйдык. «Һәрвакытта да болай булмас» дигән кагыйдәне белмәдек. Бүген иртән «Цифрлаштыру министрлыгы коммуналь хезмәтләр өчен кәгазь квитанцияләрдән баш тарту мөмкинлеген өйрәнә» дигән юлларны укыдым да бер көлдем, бер еладым. Мәгълүматлаштыру тармагының чамасыз алга китүе сәбәп түгел бит бу хәлгә, кәгазь кытлыгы мәҗбүр итә шулай эшләргә. Мәгълүматлаштыру дигәнендә дә без программалар белән тәэмин ителеш ягыннан чит базарларга нык бәйләнгәнбез. Электрон җиһазлар хакында әйтмим дә инде. Берничә айдан соң безгә интернетның акрынаюын, аңа түләүнең башка схемасын вәгъдә итәләр. Күпме мәгълүмат алдың, шуның кадәр түлисең. Видеолар карап утырасың икән, банк картаңның бик тиз бушавы ихтимал. «Госуслуги»га кереп, электрон квитанция буенча акчаңны күчерәсең дә тиз генә өзеп куясың интернетны. Әле бу хәлгә җитмәдек җитүен, бәлки, җитмәбез дә. Курск өлкәсе губернаторы Роман Старовойт үзәкләштерелгән җылылык системасының торбаларындагы суга я буяу кушарга, яисә сероводород өстәргә дигән фикергә килгән әнә. Ник дисәң, суга түләмәс өчен, өлкәнең креатив халкы җылылык торбасына кран ялгый да суны шуннан агызып ала икән. Хәзер губернатор, буяу гына кушсаң, төсле суда да ванна керерләр дип борчыла, иң яхшысы – күкертле водород катнаштыру дигән фикерне куәтли. Күкертле водородның ни икәнен беләсездер инде? Белмәсәгез, чәберчек йомырканы ватып карагыз.

Сәнәгать өлкәсендә дә шулай иҗади фикерләп, авыр хәлдән чыгарга омтылучылар бар, диләр. Монысы рәсми мәгълүмат кырына чыкмады, әмма ышанычлы чыганактан алынды. ТЭЦларда (җылылык электр станцияләре) пар казаннары күгәрмәсен өчен, техник суга гидразин дигән матдә куша торган булганнар. Гидразин судагы кислородны бетерә икән, кислород булмагач, күгәрү процессы да бармый инде. Гидразин исә дефицитка әйләнгән. Импорттан инде. Ул булмагач, чарасыздан суга аммиак куша башлаганнар. Аммиак та шул функцияне башкара, ди. Әмма аның бер хәтәр ягы бар: ул җиз детальләрдәге бакырны ашый. Җылылык системасында җиздән башка булмый. Кичекмәстән гидразин импорты торгызылмаса, берничә айдан соң технологик катастрофалар артырга мөмкин. Бу хәвефләр турында уйлаучы, алардан котылу юлларын эзләүче җитәкчеләр бардыр инде...

Менә рәсми хәбәрләрдәге оптимизм ошый. Хөкүмәт җитәкчесе чыгып: «Эшләр харап», – дисә, нинди паника кубасын барыбыз да беләбез. Паника куптымы, эшләр тагын да начарга китә. Әмма чынбарлыкка аек күз белән карау да кирәк. Үзәк банк быел банк системасының 3,5 триллионнан алып 5,8 триллион сумга кадәр зыян күрәчәге турында рәсми белдерү ясады. Бу юлларны язучы, банк югалтулары 8 триллион сумга тиң, дигән хәбәр дә алды. Үзәк банкныкына каршы килми ул хәбәр. Банк балансларындагы кыйммәтле кәгазьләрнең бәясе чүпкә әйләнү сәбәпле, тагын кимендә 2 триллион сум акча юкка чыкты инде, диләр. Сумма 8 триллион тирәсе, бәлки, аннан да күбрәк булыр. Юк, банкларны хөкүмәт терәр, әлбәттә. Алар җимерелсә, икътисадтан тузан гына калачак. Ләкин кечкенә банкларның хәле мөшкел булыр, күбесенә ябылырга да туры килер, диләр белгечләр. Хәзерге вакытта исә банклар офисларын киметәләр. Бу – эшсезләр саны арта дигән сүз. Мәскәү кредит банкы башкаладагы 6 офисын япты яңа гына.

Балык импортлау өчтән бер өлешкә кимергә тора. Кара хәбәрләр саный дип әйтмәгез. Бу хәбәрдә бизнес өчен зур уңай як бар. Бүген син эшсез калгансың икән, яисә керемнәреңнән канәгатьләндермәсә, балык үрчетү перспективасын өйрәнә аласың. Бездән күпкә авыррак хәлдәге әфганлылар әнә берничә ай эчендә балык үрчетүнең масштаблы проектларын тормышка ашыра башладылар. Аларда вазгыять бездәгедән күпкә катлаулырак, күп провинцияләрдә натураль ачлык хөкем сөрә. Әмма кул кушырып, тик ятмыйлар, шуңа күрә фәкыйрьлектән чыгулары өметле. Сүз уңаеннан әйтик инде: әфганлы крестьяннарга наркотик матдәләр алырга мөмкин булган үсемлекләр игүне тыйдылар. Американнар баскынлыгы чорында чәчәк аткан наркотиклар сәүдәсенең тамырына балта чабып аталар. Бу хакта «Российская газета»ның «Телеграм» каналы хәбәр итә. Табышны югалткан крестьяннарга башка культуралар игәргә туры киләчәк.

Без Әфганстан хәлендә үк түгел әле. Әмма безнең бизнесны да селкенергә, чишелешләр эзләргә һәм табарга мәҗбүр итә торган вазгыять көннән-көн көчәя. «Интерфакс» апрель аенда нефть чыгаруның 4 процентка кимегәнен хәбәр итә. Бер карашка начар хәбәр кебек инде, әмма моңарчы төшә алмаган нефть энәсеннән төшәргә мәҗбүр итәчәк. Һәрбер яңалыкның икенче ягы булмыйча калмый. Аңа менә шул яктан карарга туры киләчәк. Әлегә Россия бизнесы аптыраш хәлендә икән. Бөтенроссия тышкы сәүдә академиясенең Житештерүчәнлекне күтәрү үзәге бары тик предприятиеләрнең 6 проценты гына чит ил компанияләре киткәннән соң бушап калган базарны үз кулларына алырга әзер булуын әйтә. Бизнесның 70 проценты чималга һәм логистикага бәйләр күтәрелү, комплектлаучы детальләр юклыктан зарланып утыра. 21 проценты клиентлар юклыгыннан төшенкелеккә бирелгән. Башка сәбәпләрдән зар елаучылар да байтак.

«Бу хәлләр кайчанга кадәр барыр?» дигән сорауга җавап эзләп әйдә. «Российская газета» каналы АКШның Берләшкән штаблары комитеты җитәкчесенең Украина тирәсендәге кризис илларга сузылу ихтималы турында белдерүен элде. Шул ук генерал Марк Милли державалар арасындагы бәрелеш ихтималлыгы да кире какмый. Элек әбиләр әйтә иде бит әле: «Махсус хәрби операция генә була күрмәсен», – дип. Хәзер операциянең дөньякүләмгә күчмәвен теләргә генә кала.

Хәл бер бездә генә түгел, дөнья күләмендә катлаулана. АКШтан мамыкка бәяләрнең кискен күтәрелүен хәбәр итәләр, пальма маеның (россиялеләрнең төп ризыгы) бәя рекордлары куюы ишетелә (ягулык итеп файданучылар арта чөнки), АКШта кош гриппы дип миллионлаган кошны пычак аша үткәргәннәр...

Хәбәрләр тезмәсен дәвам итеп тормыйк. Бу хәл күпмегә барыр да, безнең икътисади хәл ничек булыр? Шушы сорауга җавап биреп карыйк. Автор бу юлларны язар алдыннан Ирандагы хәлне өйрәнде. Фарсыларга пассионарлык җитми дип әйтеп булмый, бик омтылышлы халык. Санкцияләр шартларында яшәгән берничә елда аларның эчке тулаем продукты 3 тапкыр кимегән, эшсезлек 15 процентка җиткән еллар булган. Россиягә катырак керттеләр тыюларны һәм өстәп торалар. Якын киләчәктәге вазгыятьне менә шуннан чыгып күзаллагыз.

2020 елда пандемия башлангач, күпчелек аналитиклар 20 ел тирәсе авыр кризис вәгъдә иткән иде. Без 5–7 ел эчендә авырлыклар эченнән чыгарбыз дип фаразладык. Ике елны үттек инде, бик авыр тагын 3–5 ел тирәсе бар дип уйлыйк. Без ялгышырга мөмкин, әлбәттә. Шулай да дөньякүләм зур мәтәлчек шартларында шуннан да ким яшәмәбез. Әмма язманың исеменә карыйк: һәрвакытта да болай булмас.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Йөгәнләү мөмкинме?

Күптән түгел Россия Дәүләт Думасының Мәгълүмат сәясәте, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә комитеты башлыгы Александр Хинштейн ил халкының шәхси мәгълүматларын яклауны көчәйтүгә бәйле чаралар турында фикерен җиткерде. Сүз мәгълүматны эшкәртүче операторларга карата таләпләрне катгыйландыра торган закон проекты турында бара. Барысына да «Яндекс. Еда» хезмәте белән бәйле ыгы-зыгы сәбәпче. Хәтердә яңартыйк: «Яндекс.Еда» хезмәтеннән кулланучыларның шәхси мәгълүматы (исем-фамилиясе, яшәү урыны, нинди һәм ничә сумлык заказлар ясавы) интернетка эләккән иде. Хинштейн сүзләренчә, бу очрак россиялеләрнең шәхси мәгълүматы ни дәрәҗәдә саклануын ачык күрсәтте.

Парламент вәкиле әйтүенчә, бу вакыйга куркынычсызлык һәм мәгълүматны саклау сыйфатына гына бәйле түгел. «Әйтик, шәхси мәгълүматны эшкәртүче операторлар, гомумән, дәүләтне шундый очрак турында кисәтергә тиеш түгел. Ягъни Россия мәгълүмат ресурсларына компьютер һөҗүме нәтиҗәләрен ачыклау, кисәтү һәм бетерү буенча дәүләт системасы операторлары арасында бернинди дә хезмәттәшлек итү юк», – дип борчыла Хинштейн. Менә шушы элемтә нигезендә, бәлки, онлайн урлашулар да кимер иде дигән фикер бар.

– Шул ук вакытта операторлар, әйтик, банклар, гражданнардан шәхси мәгълүматларны гына түгел, биометрик мәгълүматларны да (кешенең физиологик һәм биологик үзенчәлекләре, аның нигезендә шәхесне билгеләргә мөмкин. – **Ред.**) тапшыруны таләп итә. Юк икән, хезмәт күрсәтүдән баш тарту белән яный. Моның өчен алар нинди дә булса җаваплылыкка тартылмый, – ди комитет җитәкчесе.

Александр Хинштейн россиялеләрнең күчемсез милек турындагы мәгълүматлары шулай ук шәхси мәгълүмат булып тора дигән фикердә. «Бүген теләгән һәркем бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына (ЕГРН) мөрәҗәгать итеп, теләсә кайсы гражданин турында, аның милке турында мәгълүматны сората ала. Төгәл адреслары белән! Бер караганда, без, кеше үзенең шәхси мәгълүматлары белән мөстәкыйль рәвештә эш итәргә һәм аларга чит кеше керүен чикләргә хокуклы, дибез. Икенче яктан, шул ук милке турындагы мәгълүмат очрагында карасак, барысы да ачык. Бу, әлбәттә, дөрес түгел», – дип саный ул.

Хинштейн тәкъдим иткән закон проектында нинди таләпләр бар соң? Бу – иң элек, операторларга бер тәүлек эчендә шәхси мәгълүматның башкалар кулына эләгүе турында хакимият органнарына хәбәр итү бурычын кую; мәгълүматның башка дәүләтләргә чыгуына бәйле эшне көйләү; милекче рөхсәтеннән башка шәхси милек турында мәгълүматны өченче затларга бирүне тыю.

Нәтиҗәсен көтәләр

Хокук һәм финанс белгече Ләйсән Халикова депутатлар тәкъдим иткән закон проектыннан файда булыр дип өметләнә.

– Мәгълүмат агымы шулкадәр көчле, безнең бар тормыш интернет мәйданчыкка күчте. Безнең хакта барлык мәгълүмат та шунда әйләнеп йөри. Әлеге канунны кабул итсәләр, безнең шәхси мәгълүматны саклауга бер адым булыр дип уйлыйм, – ди ул. – Әлбәттә, махсус федераль закон да, аңа карата җәзасы да бар. Әмма безнең шәхси мәгълүматны саклаучы операторларга безнең хактагы мәгълүматларны тараткан өчен штраф әллә ни зур димәс идем. Шул сәбәпледер дә, алар ул мәгълүматны уңга-сулга җиңел генә таратырга мөмкин.

Үзебез турында мәгълүматны бөтен җирдә таба алабыз үзе: телефонга SIM-карта сатып алсак та, банкта исәп-хисап счеты ачсак та. Шул ук «Дәүләт хезмәтләре» порталында да. Әмма, хокук белгече фикеренчә, аңа да тулысынча ышанырга мөмкин түгел.

– Рәсми сайт дисәк тә, аңа ышанычым түбән. Андагы мәгълүматны җиңел генә кулга төшерергә мөмкиннәр дип уйлыйм. Үз тәҗрибәмнән дә чыгып әйтә алам: күпләр үзләре исеменә микрозаймнар рәсмиләштерү турында хәбәр итә. Шушы сайтта сакланган мәгълүматлар буенча бу. Әлбәттә, нәкъ тә бу порталдан безнең мәгълүматлар киткән дип әйтеп булмый. Әмма «Дәүләт хезмәтләре» порталына да көчлерәк сак кирәк дигән фикердә мин, – ди Ләйсән Халикова.

Мәгълүмат белән кеше үзе дә сак кыланмый. Проблемаларның башы үзебездә, димәк. Белгеч сүзләренчә, шәхси мәгълүматны саклау турындагы килешүне имзалаган вакытта да игътибарлы булырга кирәк. Анда «эшкәртү, саклау» сүзеннән тыш, «башка партнерларга тарату ихтималы» дигән җөмлә дә очрарга мөмкин. Бу күбрәк банк килешүләрендә күзәтелә. Онлайн операцияләр башкарганда да шул ук кагыйдәне истә тоту, теләсә кайсы урынга имза-билге куймау сорала. Һәр билге рөхсәт буларак кабул ителергә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЧЫК КАПКА

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Терсәкне тешләп булмый

Мәгълүматның төрле сәбәпләр белән башкалар кулына эләгүе даими күзәтелә, дидек. Интернетта әледән-әле социаль челтәрләрдәге парольләр, исем-фамилия, адреслар кертелгән яңа базалар чыгып тора. Сезнең хакта мәгълүмат та намуссыз затлар кулына эләккән булса, нишләргә?

Иң төп кагыйдә – артыгын берни эшләмәскә. Ягъни мәгълүмат тупланган сайт, база сылтамаларын ачмаска. Бу сездә булган бөтен төр мәгълүматның да башкалар кулына эләгүенә китерергә мөмкин.

Мәгълүмат социаль челтәрләр белән бәйле икән, **иң беренче эш итеп сәхифәләрегезнең парольләрен алмаштырырга**, мәгълүматның ни дәрәҗәдә саклануын тикшерергә кирәк.

Банкка бәйле мәгълүматларыгызга намуссыз кешеләр кулы сузылган очракта нишләргә? Шуны белеп тору кирәк: банкка счеттан акча урлау турында бер тәүлек эчендә хәбәр итеп өлгерсәгез, куркынычсызлык кагыйдәләрен бозмасагыз, закон буенча банк сезгә акчаны кире кайтарырга тиеш. Әлбәттә, әгәр дә сез мошенникларга бернинди мәгълүматны үзегез тапшырмаган, сылтама, смс-хәбәрләргә җавап бирмәгән очракта.

Мәгълүматны куллану буенча канун үтәлешен тикшерүче Роскомнадзорга мөрәҗәгать итәргә дә мөмкин. Хәтта үзегез хакында мәгълүматка тап булган сайт-сылтамалар турында әйтергә, нинди мәгълүматлар кулланылганын күрсәтергә кирәк булыр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, россиялеләрнең 37 проценты шәхси мәгълүматларының ни өчен һәм ничек кулланылганын белми. Халыкның яртысыннан артыгы (62 проценты) исә файдалану максатлары турында хәбәрдар.

Россия прокуратурасы статистикасына караганда, мәгълүмати базаны урлауга бәйле җинаятьләрне ачыклау күрсәткече 25 проценттан да артмый.

ФИКЕР

Айрат НУРЕТДИНОВ,
«Таттелеком» җәмгыяте генераль директоры:

– 2020 елга кадәр куркыныч тудыра торган сайтларны томалау белән операторлар шөгыльләнде. Суверен интернет турында закон кабул ителгәч, моның белән Роскомнадзор шөгыльләнә башлады. Барлык операторлар челтәрендә куркыныч тудыра торган һөҗүмнәргә каршы торуның техник чаралары куела. Бу – Россиядә тарату тыелган мәгълүматны чикләүче аппарат комплексы (ТСПУ).

Интернеттан кулланганда мәгълүмати куркынычсызлыкны программа тәэминаты (программное обеспечение) һәм провайдерлар тәэмин итә. Алар төрле һөҗүмнәр турында хәбәр сала. Мәгълүматка ия булуның иң киң таралган төре – компьютерга DDOS-һөҗүм, челтәрара экран (Firewall. – **Ред.**), кушымталар, гаджетның эчлеге, яңарту программалары (обновление) аша һөҗүм.

Беләсезме, еш кына киберһөҗүмнәр хакерның акыллы булуыннан түгел, кеше баш миенең ничек эшләвенә һәм кешенең теге йә бу очракта нинди карар кабул итеп эш итүенә барып тоташа. Хакер моны белә. Шуңа күрә әле дә социаль инженерия, психологик тәэсир итүне кулланалар. Мәгълүмати куркынычсызлык өлкәсендәге танылган шәхес, шулай ук элеккеге компьютер хакеры Кевин Митник әйткән бит әле: парольгә куркынычсызлык системасын җимерүдән битәр алдау ысулы белән ия булу күпкә җиңелрәк.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ЧАРАСЫЗЛЫК

АГРОФИРМАДА ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ НИК АЗ?

Редакциягә борчулы шалтырату килеп иреште. «Апас-мол» агрофирмасында эшләүче терлекчеләр хезмәт хакларының аз булуыннан, аны да вакытында түләмәүләреннән һәм фермада үлгән бозаулар өчен акчаларын тотып калудан зарланды. Әлеге мөрәҗәгать буенча без Апас районына бардык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Бер тиен акчабыз юк»

Редакциягә шалтыраткан Люция Сәлахова Колгына авылында яши. Эшкә исә өч чакрым ераклыктагы Дәвеш авылы фермасына барып йөри. Егерме елдан артык фермада эшләүче тәҗрибәле терлекче. Баштагы елларда сыер сауган, дүрт ел элек яшь бозаулар карауга күчкән.

– Эшебез иртәнге сәгать 4тә башлана, – ди ул. – Сигездә кайтабыз да, төшке аш вакытында кабат барып, ике сәгать эшлибез. Кичен тагын 4,5 сәгать фермада булабыз. 170 бозау карыйбыз. Асларын чистартабыз, ашарларына салабыз. Эше күп, тик түләве бик аз. Без эшлибез, ләкин ничә сум хезмәт хакы аласын да, ни өчен шулай аз чыгуын да белмибез, чөнки кәгазь бирүче, аңлатучы юк, – дип аңлатып бирде ул четерекле хәлне.

Яңа танышыбыз сүзләре буенча, терлекчеләрнең хезмәт хакларыннан үлгән бозаулар акчасын тотып алып калалар.

– Бозау карауга күчкәннән бирле, ягъни дүрт ел дәвамында яшь маллар үлгән айда аның акчасын тотып алып калалар. Бернинди документка кул кую юк. Башта икешәр мең сум алып калдылар, соңгы берничә айда дүртәр мең сумны кыса башладылар. Әле анысын да белми йөрер идек. Бу айда мин хезмәт хакы хисабына ике бозау яздырып алмакчы идем. Шул турыда язылган кәгазь артына февраль хезмәт хакын 2400 сум дип күрсәткәннәр. Аласы акча аз булгач, бер генә бозау бирделәр. Сораша башлагач, дүрт мең сумны тотып алып калган булып чыктылар. Ә бозаулар күп үлә, чөнки тиешле карау юк. Кыш буе тәрбия күрмәде алар. Бер айда 18–20 бозау үлгән очраклар булды, – ди ул.

«Моңа кадәр түздек, хәзер инде чама калмады», – ди Люция Сәлахова.

Люция Сәлахова сүзләренчә, үлгән бозаулар өчен акчаны терлекчеләрнең хезмәт хакыннан тотып калу элек тә булган. Соңгы елларда бу бигрәк тә ешайган. Мондый хәл күрше-тирә авылларда юк, ди ул.

Люция Сәлахова әйтүенчә, агрофирмада эшләүчеләр болай да аз хезмәт хакы ала.

– Гыйнварда кулга 14 мең сум алдым. Бу безнең өчен бик күп дип санала инде. Гадәттә уртача яхшы хезмәт хакы 12 мең сум дип бара. Елга бер-ике тапкыр 18 мең дә алган булды. Без генә түгел, сыер савучыларның да кесә тутырып акча алганнары юк. Дүшәмбе көнне район башлыгы янына барган идем, ул ялда булу сәбәпле, керә алмадым. Шуннан кайткач, февральгә 6 мең сум акча күчте. Белешә башлагач, бозау өчен дип алган 4 мең сум акчаны да кире кайтарырга куштылар, дип аңлаттылар, – ди ул.

Терлекче, агрофирмада хезмәт хакын тоткарлыклар белән түлиләр, ди. Апрельдә февраль акчасын алу – халык өчен зур бәхет. Әле җитмәсә, шул аз акчаны да ике-өчкә бүлеп түлиләр икән.

– Хезмәт хакы булмагач, халык эштән китеп бетте. Алар урынына өч үзбәкне алып килделәр. Бар кеше канәгатьсезлек белдерә. Ләкин авызыбызны: «Барыгыз, кайтып китегез. Эш тагын каян табасыз?» – дип кенә ябалар, – ди ул.

Сәлаховлар – ишле гаилә. Ике балалары инде үзләре дә гаилә корган, өчесе әле мәктәп укучысы гына. Люция апаның ире дә 35 ел шушы агрофирмада механизатор булып эшләгән. 12 мең сумнан артык хезмәт хакы алмаган. Узган ел, тормыш итәргә акча җиткерә алмагач, фермадан китеп, Дәвеш авылындагы фермерга эшкә урнашкан.

– Мондый шартларда тормыш итү бик авыр, – ди биш бала анасы. – Дүшәмбе көнне 6 мең сум алганчыга кадәр, өйдә бер тиен акчабыз юк иде. Сыерыбызда лейкоз чыккач, аны тапшырырга туры килде. Яңаны алырга акча җиткереп булмый. Ике үгез, бозаулар, кош-кортлар тотабыз.

Бозаулар өчен түләү

Люция Сәлахова сүзләре буенча, үлгән маллар өчен акчаны яшь бозау караучы, ферма мөдире, осеменатор, мал табибының хезмәт хакыннан тотып калалар. Соңгысы исә, түзә алмыйча, шулай ук эшен калдырып кайтып киткән. Бу вазгыятькә карата әлеге фермада 2005 елдан бирле мал табибы булып эшләгән Дамир Сөләймановның фикерен беләсебез килде.

– Хезмәт хакыннан үлгән бозау өчен тотып калу дигән нәрсә күптәннән бар инде ул, – диде ул безгә. – Ай саен бер, я ике бозау өчен акча түлибез. Түләмәгән айлар сирәк. Бер бозау өчен якынча 2 мең сум алып калалар. Минем бер ставка хезмәт хакым – 17,5 мең сум. Түләү һәм башка чыгымнардан соң ашарга да акчам калмый. Күрше авылдан килеп йөрим. Шушы ике арада йөреп, машинаны туздырдым. Шуңа күрә эштән китәргә мәҗбүр булдым.

Мал табибы фикеренчә, бозаулар үлүнең төп сәбәбе – вакцина схемасының дөрес булмавы.

Әлеге ферманы без дә барып күрдек. Кызганыч, әйләнә-тирәсе бик пычрак булу сәбәпле, эченә үк уза алмадык. Шулай да берничә терлекче белән күрешеп сөйләшә алдык.

– Монда хезмәт хакы бик аз. Мал караучылар 5 мең сум акча ала. Авыру терлекләр дә күп. Мал табибы юк бит монда, – диде безгә исемен әйтергә теләмәгән бер терлекче.

Үзен Ландыш дип таныштырган апа килешү белән эшли икән. Әлеге вакытта Люция Сәлаховасы алыштыра.

– Мин 20 мең сум акча алам. Килешү нигезендә эшләгәч, вакытында түлиләр, – диде ул.

Безнең сөйләшүгә сыер савучы Талия дә килеп кушылды.

– Алты-җиде мең сум акча алам. Бик аз инде хезмәт хаклары. Кибеткә керер хәл юк, бәяләр котырып арта. Акча бернигә дә җитми. Бездә иң югары хезмәт хакы – 12 мең сум. Тана өйрәтүчеләр күбрәк ала үзе, – диде ул.

Гаеп атта да, тәртәдә дә

«Апас-мол» агрофирмасының Горбунов бүлеге зоотехнигы Илсур Хәсәнов җаваплылыгында алты бүлекчә. Барысында бергә 4500 баш мөгезле эре терлек исәпләнә. Шуларның 2 меңе – сыерлар. Фермаларда якынча 200ләп кеше эшли.

– Терлекчеләргә хезмәт хакын эшләүләренә карап түлибез, – диде җитәкче. – Бер баш бозауны исән-сау үстерсә, эшчегә 500 сум языла. Шулай ук хезмәт хакы алганда малларның никадәрле авырлык җыюына да игътибар итәбез. Бозау караучыларга ел ахырында өстәмә кызыксындыру чарасы да каралган. Бозауларның 95 проценты исән-имин калган очракта, 45 килограммлы үгез бозау бирәбез. Сыер савучыларга хезмәт хакы сөт күләменә һәм сыйфатына карап түләнә. Моннан тыш, башка төр өстәмәләр бар. Шуңа күрә терлекчеләр арасында 17 мең алучысы да, 25 меңгә эшләүчесе дә бар. Намус белән тырышып эшләгәннәрне ким-хур итмибез. Әйе, 12 мең сум алганнар да бар. Мөмкинлеккә карап инде. Яшермим, быел авырга туры килде.

Илсур Хәсәновтан үлгән бозаулар өчен хезмәт хакыннан тотып калу очраклары турында да сораштык. Аның әйтүенчә, бу сүзләр дөреслеккә бик үк туры килеп бетми.

– Терлекчеләр аны бик аңлап бетерми. Үлгән бозау өчен алынса да, ул акчаны башка җай чыгарып, барыбер түлибез. Сезнең белән сөйләшкән Люция очрагында хәлләр менә болайрак. Ул хезмәт хакы исәбеннән бозау яздырып бирүемне сорады. 78 килограммлы бозау алган. Ләкин шул көннән соң эшкә чыкмады. Эш шунда ки, күптән түгел генә агрофирма капчыгын 2500 сумнан шикәр бирде. Люциянең хезмәт хакыннан шуны да тотып калдылар. Нәтиҗәдә кулына 2300 сум акча аласы булган. Ләкин ахырдан аңа 6 мең сум күчергәннәр. Шунысын да искәртим: бездә хезмәт хаклары бүлеп тә түләнә.

Җитәкче әйтүенчә, аз хезмәт хакы алуда терлекченең үзенең дә гаебе бар.

– Тулы ай эшләгән вакыты сирәк аның. Үрнәк терлекче булса, ел ахырында бозавын җитәкләп кайтып китәр иде. Декабрьдә – 7, гыйнварда 23 көн эшләгән. Елына 263 көн эштә булган. Аның елга уртача хезмәт хакы 15 мең сумнан артык чыккан. Төрле кеше бар. Ферма бетә, эшсез калабыз, дип тын алырга

ТАРМАКТА ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат үзәге биргән мәгълүматлардан күренгәнчә, узган ел нәтиҗәләре буенча, авылда уртача хезмәт хакы бер эшчегә 32480 сум туры килә. 2020 ел белән чагыштырганда, үсеш 23 процентны тәшкил итсә дә, республиканыкыннан 27 процентка кимрәк. Авыл хуҗалыгы тармагында иң югары хезмәт хакын Яшел Үзән районында алалар. Биредә «Майский» теплицасында уртача хезмәт хакы – 55,2 мең, «Ак барс» кошчылык комплексында 42,9 мең сумны тәшкил итә. Тукай районында да хезмәт хаклары яхшы (44,8 мең сум). Аның дәрәҗәсен 50,8 мең сум белән «Челны Бройлер» һәм «Камский Бекон» (51,1 мең) күтәрә. Моннан тыш, узган ел Чистай (33,2 мең) һәм Мамадыш (44,3 мең) районнарында күтәрелеш сизелде. Районда уртача хезмәт хакы 35 процентка арткан. Шулай ук Тәтеш, Аксубай, Актаныш районнарында да хезмәт хаклары даими рәвештә үсештә һәм башка тармаклардан күпкә калышмый.

Хуҗалыкларга килгәндә, Әлмәт районының «Союз Агро» (60,5 мең), Бөгелмә районының «Тәньяк Нива» (45,5 мең), Буа районының «Акыллы ферма», Аксубайның «АФ АксуАгро», Чүпрәленең «Цильна», Тәтешнең «Бакырчы», Чирмешәннең «БиоАгро» җәмгыятьләрендә уртача хезмәт хакы 43 мең сумны тәшкил итә. Ә Әтнә районының «Дусым» агрофирмасында сыер савучылар – 49,8 мең, Мөслим районының «Август-Мөслим» оешмаларында 42 мең сум ала.

Быел тармактагы уртача айлык хезмәт хакын уртача икътисад буенча 80 процентка кадәр күтәрү бурычы куелган.

курkып торучылары да шактый. Ә бу апа район башлыгына кадәр барган, – диде Илсур Хәсәнов.

Агрофирмадагы вазгыять буенча Апас районының авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Радик Гыйсмәтовка да чыктык.

– Әйе, сезнең килгәнне дә беләбез, – дип сүзен башлады идарә җитәкчесе. – Мин бу хәлне контрольгә алып тикшерттем. Люция Сәлахова сүзләре дөреслеккә бик туры килеп бетми. Февраль аена аңа 16 мең сум хезмәт хакы чыккан. Шикәр, хезмәт хакы хисабыннан бозау яздырып алган булган, аның өчен тотканнар. Дөресен әйткәндә, Люциянең үзенең дә гаебе бар. Эшен җиренә җиткереп үтәмәгән. Гаеп ике якта да бар дип саныйм, чөнки «Ак Барс» агрохолдингының хәле авыррак. Терлек азыгы җитеп бетми. Продукция аз булгач, эшчеләрнең хезмәт хаклары да күп түгел. Шуның өстенә вакытында да түли алмыйлар. Әлегә март аеныкы кучмәде, февраль өчен ала гына башладылар. Әйе, чыннан да, бозау үлгәч, акчаны тотып калырга, дигән приказ бар. Ләкин, закон буенча, аның 20 проценты гына тотылырга тиеш. Монда шулай булган да. Ферма белән идарә итүче егет Люцияне эшкә чакырып барган, тик әлегә ул чыкмаска булган.

Яхшының, матурны гына күрсәтү барыбызга да күңелле анысы. Булдыклыларын да, тырышларын да, гөрләп торган тормышларны да. Тик авылның проблемалары да җитәрлек. Авыллар бетә, эшләргә кеше юк, дип бик еш ишетәбез. Тик шундый шартларда яшәгән, кулына аз хезмәт хакы тигән, анысын да вакытында ала алмаган халык букчасын сыртына салып авылдан чыгып китәргә мәҗбүр була шул инде...

ИКЕ КУЛДА... МЕҢ ҺӨНӘР

Балтач районының Иске Салавыч авылында яшәүче Рамазан абый Фәрзиевнең һөнәрләрен, мавыгуларын санап чыгу гына да җиңелдән түгел. Балта остасы, токарь, җиһаз ясаучы, данлыклы бакчачы, яшелчә үстерүче, умартачы... Җиде дистәсен түгәрәкләп килсә дә, әле дә тик торганы юк.

Рамазан Фәрзиевнең шәхси архивыннан

Безнең чор балалары өчен ул сызым, хезмәт дәресе укытучысы булып калды. Гап-гади балта-пычкы, ышкы кебек кораллар белән өйләрен тышлаган, челтәрле кәрнизле веранда ясаган егетне ул чактагы директор Нәкыйп абый Шәфигуллин мәктәпкә чакырып алгышмый. Үнкиде ел балалар белән яратып эшли: яшүсмерләрне кадак-чүкеч тотарга, көйдереп-кырып сувенирлар ясарга өйрәтә. Әле дә урта яшьтәге ир-атлардан рәхмәт сүзләрен күп ишетә ул.

Мәктәптән киткәч, район үзәгендәге төзелеш оешмасына... токарь булып эшкә урнаша Рамазан абый. Агач эшендә азмы-күпме тәҗрибәм бар, калганын шунда өйрәнермен ди дә тәвәккәлли... Бу эшкә дә сәләте ачыла. Ә бераздан әлеге оешма агачтан җиһазлар ясый башлый. Нәрсә генә ясамыйлар: арка терәгечле йомшак урындыклар, ашханә һәм банкет өстәлләре, өсләре ярымтүгәрәк формада булган тәрәзә рамнары, ишекләр, караватлар... Кибетләрдә җиһаз кытлыгы булган еллар бу, заказлар явып кына тора.

Тынгы белмәс Рамазан абый өендә үз остаханәсен булдыра: төрле станоклар, кораллар сатып ала, бик күбесен үзе ясый. Эштән соң, ял көннәрендә авылдашларының, таныш-белешнең заказы буенча төрле җиһазлар ясый: әле дә күп йортларда ул сырлап, матурлап ясаган, ныклыгы-чыдамлыгы белән аерылып торган тахта-караватлар, өстәл-урындыклар саклана. Моңа кадәр яшелчәче, бакчачы буларак танылган Рамазан абый бу һөнәре белән дә дан казана.

Кайдадыр теплицалар бүгенге чорда бик популяр, яңалык булса, Рамазан абый безнең якларда бу өлкәдә 45 ел элек үк инде «беренче карлыгач» булды. Иртә язда өлгергән кыяр-помидорларны гына түгел, үсентеләрне дә сатып акча эшләп булуын да башлап ул күрсәтте. Утыз еллап шөгыльләнгәч, туеп түгел, яңа йорт салырга урыны кирәк булганга, теплицаларын киметергә мәҗбүр була. Хәзер үзләре өчен генә үстерәләр.

45 ел стажы булган умартачы да әле ул. Монысын әле дә дәвам итә. Хәзер инде ярдәмчеләре күп: улы, оныклары да ул үз иткән һөнәрләрне якын күрә. «Алма агачыннан ерак төшми» дигән сүзләр улы Раушанга бигрәк туры килә. Анда да әтисе сыйфатлары бар – нәрсәгә тотынса, шуны булдыра. Токарь да (хәзер инде өйләрендә мондый станок та бар), агач эшенә дә кулы ятып тора, техникада да булдырып эшли.

Үткән яз әтиле-уллы Фәрзиевләр үтә дә кызыклы җайланма эшли. Идеясе Раушанныкы була. Интернеттан күреп, үзләренчә үзгәртеп, алар гап-гади полиэтилен табактан... тавык, үрдәк, каз йолкый торган җайланма ясый.

– Бер фазалы электр энергиясе белән эшли. Зуррак табакка бар яктан, махсус тешләр-тырнаклар димме, беркетелгән. Аскы өлештә су һәм йоннар агып торыр өчен тишем бар. Тавык-чебешне башта кайнар суга тыгып, кайнарлыйбыз (кайдадыр, пешеклибез, диләр). Аннан шушы табакка салып, токны тоташтырасың. Өстән лейка белән аз-азлап су агызып торасың, корыга калып, тиресе ертылмасын өчен кирәк бу кадәресе. Санаулы минут эчендә канатларына кадәр йолкып, чистартып бетерә. Үрдәкне дә җиңел чистарта. Казларны беркадәр тәртиплисе була, аларга зуррак савыт кирәк, ахрысы, – ди Рамазан абый.

Корал эшли, ир-ат мактана, ди халык мәкале. Кайчакта мондый сүзләр белән килешәсе дә килми. Ул кораллар бит Рамазан абый кебекләр кулында гына остага әйләнә...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Язучы фикере

Зарланырга ярамый

Иzарланабыз инде без! Ил башлыкларыннан да, үзебез эшләгән оешма җитәкчеләреннән дә, гомумән, бөтен нәрсәдән дә зарланабыз. Сәбәпләре дә табылып тора аның. Әле хезмәт хакы артмый, әле бәяләр күтәрелә, әле эшләгәнне күрмиләр, әле эшләмәгәнне күрәләр. Сәбәпләре дә санап бетергесез инде аның. Шулай булгач, мөмкинлек чыккада, үзеңне күрсәтеп калырга тырышасың. Зарлану шуннан хасил була.

Бер мәлне авылга кайттым. Хастаханәдән чыккан гына чак. Кул-аякларның рәте юк, буыннар сызлый. Кар гына ямысын иде, димен. Белгән бөтен догаларны укып бетердем. Югыйсә кар да көри алмый ятачаксың бит инде ир башың белән. Тик торганда да тыңгы бирмәгән сызлану, эш эшләсәң, көчәеп кенә китә бит инде. Өстәвенә табиблары да кат-кат кисәтеп кайтарды... Юк! Икенче көнне ишеп кар явып китте. Мин үземне кеше сүзенә бик исе китми торган адәм диебрәк уйлый идем. Алай түгел икән. Кар көрәргә йөрәк җитмәде. Күршеләр күрер дә я ялкау, я чиргә уралган, я исерек дип уйларлар кебек тоелды. Шуңа кар баскан урыннарга көне буе карап, эчем пошып йөрдем дә, караңгы төшкәч, көрәп бетердем. Әкрен генә, көчем җиткәнчә генә итеп. И сөендем инде үземнең кар көри алуыма! Ходай да сөенде бугай, мин көрәп бераз торгач, тагын яудырырга тотынды. Анысын иртән, кояш чыкканчы көрәдем. Кеше-фәлән күрмәде. Өченче көнгә буран чыкты һәм мин көрәгән урыннарны көрәлмәгән җирләр белән тигезләп куйды. Тагын төнне көтәргә туры килде. Шулай бер атна чамасы җәфаланганнан соң кар ямый башлады. Көннәр җылынды, өй кыегыннан тамчылар тама. Эш юклыгына сөенеп йөргән вакытта өй түбәсендәге кар ишелеп төште дә бөтен сукмакны диярлек каплап куйды. Монысы яңа яуган йомшак кар гына түгел инде, сулы, авыр, бер көрәге фәләнкило тарта торган. Ишегалдында булгач, төн җиткәнен көтмәдем инде, әкеренләп кенә ерып чыктым. Күршенең йорты да безнең ихатадагы кебек утыра. Аның өй түбәсендәге кар да безнең ишегалдына төшә. Монысын тәмамлауга мунча түбәсе...

Кемнән зарланыйм, кемне тиргим инде хәзер? Ил башлыкларынмы? Депутатларынмы? Колхоз рәисенме? Бригадирнымы? Табигатьнең тәртибе юк хәзер, бернәрсә дә даими түгел – һава торышы сәгать саен үзгәреп тора. Тик аны тиргәп булмый бит инде. Файдасыз. Тамагың ертылганчы кычкырсаң да, ул сине бар дип тә белми. Колагы ишетми дип булмый инде, безнең сүзләр аңа барып җитми, я аңлашылмый торгандыр. Безнең тел дә үз милләттәшләребез белән аралашыр өчен генә бит инде ул. Әле аларның да күбесе аңламый. Татарча белгәннәре дә. Син берне әйтсәң, алар икенче төрле ишетә. Үзләре теләгәнчә. Ә монда табигать! Ул әле үзен сиңа бик зур файда ясадым дип уйлый торгандыр. Табигатьне тиргәп булмый. Ә Ходайны – бигрәк тә. Аңа ялгыш тел тидерсәң, кар көрәп интеккән чакларың олы бәхет булып калырга да мөмкин. Алла сакласын Ходайга тел тидерүдән. Менә шулай булгач, кар күпме яуса да, аны көндәм генә көрисең дә үз эшеңнән тәм табып, тыныч кына яши бирәсең.

Яңгыр яуса да шулай. Әйтик, менә җәй көне. Эссе кояш кыздыра. Син, маңгай тиреңне кул сырты белән сөртә-сөртә, тыбын-көнең бетеп печән чабасың. Көн болай торса, кичкә җыеп алырлык булачак, дип сөенәсең. Һәм... Чабып та бетерәсең, яңгыр коеп та китә. Могҗиза инде бу. Әллә чабылган үләннең болытны тарта торган берәр көче бар ул, аңламассың. Алай түгелдер инде... Әле әйләндерә-әйләндерә киптереп, чүмәлә салам дип кенә торганда тагын явып китә. Шундый хәлләр.

Уйлап карасаң, хәтта табигать тә, хәтта Аллаһы Тәгалә үзе дә без теләгәнчә генә эшләми. Ләкин без зарланмыйбыз, булганына шөкер итеп, булмаганына өмет итеп, басынкы гына яши бирәбез. Шулай булгач, ул ил башлыклары, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр ничек без теләгәнчә эшли алсын ди инде? Хәтта бик-бик теләсәләр дә булдыра алмаслар иде. Шуңа күрә теләмиләр дә. Теләгәненнне булдырырга, булдыра алмаганыңны теләмәскә кирәк. Алар моны яхшы аңлый. Ә инде үзең теләгәнчә эшләргә уйласаң, үзең эшләргә кирәк. Анысы да гел килеп чыкмый әле.

Ә без зарланабыз... Чынында безнең зарлану, җитәкчеләрне тиргәү чын күңелдән түгелдер инде ул, һава торышы турында сөйләшкән кебек кенәдер. Һава торышын үзгәртә алмаган шикелле, илдәге вазгыятьне дә без үзгәртә алмыйбыз... Бугай...

Марат КӘБИРОВ

11 апрель | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.20 «СВОИ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ» 16+
00.00 «Год на орбите». Док. фильм 12+
00.30 «Здоровая семья: мама, папа, я» 6+
00.45 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ӘНИЕМНЕҢ ЖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 «Жить здорово!» 16+
10.00 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 Ольга Будина в телесериале «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 16+
02.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.00, 21.35, 03.00 Новости 0+
06.05 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Новости
09.05, 12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
09.25 Профессиональный бокс. Хусейн Байсангуров против Манука Диланяна. Трансляция из Москвы 16+
09.55 Профессиональный бокс. Георгий Челохсаев против Мухаммадсалима Сотволдиева. Трансляция из Москвы 16+
10.30 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
11.30, 02.40 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.05 «АГЕНТ» 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Восток». «Металлург» (Магнитогорск) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
19.15 «Громко». Прямой эфир
20.15 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волкановски против Чэн Сон Джунга. Трансляция из США 16+
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Болонья» – «Сампдория». Прямая трансляция
23.45 Все на Матч! Прямой эфир
00.30 Тотальный футбол 12+
01.00 «РОЖДЁННЫЙ ЗАЩИЩАТЬ» 16+

НТВ

05.05 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
22.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
23.30 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ПОРОХ И ДРОБЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Зов прошлого» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ МАТЕРИ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.45 «Порча» 16+
02.10 «Знахарка» 16+
02.40 «Верну любимого» 16+
03.05 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «Открытый космос». Докудрама. Фильмы 3-й и 4-й 12+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «ДЕЛО БЫЛО В ПЕНЬКОВЕ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «КРАПЛЕНЫЙ» 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Оружие непобедимых. От миномётов до «Искандера» 16+
21.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал 12+
22.15 Новости дня 16+
22.30 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.55 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №98». Премьера! 16+
23.40 «12 апреля – Всемирный день авиации и космонавтики». Док. фильм. Премьера! 16+
00.30 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-4». 1-я - 3-я серии 16+
03.00 «Одесса. Герои подземной крепости». Док. фильм 12+
03.45 «КРАПЛЕНЫЙ» 16+

12 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.15 «СВОИ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.35 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.10 «БАТАЛЬОНЫ ПРОСЯТ ОГНЯ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Василий Аксенов. Казань. Автограф на «Юности» 12+
00.50 «Здоровая семья: мама, папа, я» 6+
01.05 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.20 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Иҗәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ӘНИЕМНЕҢ ЖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 «Жить здорово!» 16+
10.00 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Евгения Брик. «НИКТО НЕ УЗНАЕТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Премьера. «Байконур. Первый на планете Земля» 12+
01.05 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 16+
02.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.00, 18.00, 03.00 Новости 0+
06.05, 18.05, 21.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «ПРОКЛЯТЫЙ ЮНАЙТЕД» 16+
11.00 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30, 02.40 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 03.05 Специальный репортаж 12+
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.05 «АГЕНТ» 16+
17.00 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
18.30 Хоккей. КХЛ. Финал конференции «Запад». ЦСКА – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Реал» (Мадрид, Испания) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
00.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Бавария» (Германия) – «Вильярреал» (Испания) 0+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. «Фламенго» (Бразилия) – «Тальерес» (Аргентина). Прямая трансляция

НТВ

05.00 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
22.00 Премьера. Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
23.30 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ПОРОХ И ДРОБЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Маленькая принцесса» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА» 16+
19.00 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.45 «Порча» 16+
02.10 «Знахарка» 16+
02.40 «Верну любимого» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «КРАПЛЕНЫЙ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 18.45 «Спец. репортаж» 16+
09.40 «ТРИ ТОПОЛЯ» НА ПЛЮЩИХЕ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «КРАПЛЕНЫЙ» 16+
20.40 «Оружие непобедимых. От миномётов до «Искандера» 16+
21.25 «Улика из прошлого» 16+
22.15 Новости дня 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии» 12+
23.40 «Гагарин. Жизнь в хронике ТАСС». Док. фильм 16+
00.45 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-4» 16+
03.10 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.45 «КРАПЛЕНЫЙ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 11–17 АПРЕЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атнада шәхси әйберегезне югалту куркынычы бар. Кемнеңдер алдашуы сәбәпле, уңайсыз хәлдә калу ихтималы да юк түгел. Шуңа күрә тирәгездәгеләр белән аралашканда саграк булыгыз, юк-бар сүзләргә ышанмагыз, дип кисәтә йолдызлар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Атна башында танышлыгыз бер четерекле мәсьәләнең очына чыгу юлларын күрсәтеп сөендерер. Эшегездә бәйле әйбәт яңалыклар ишетелер. Озакламый матди хәлегезнең шактый ук яхшыруына өметләндерердәй хәлләр килеп чыгар.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Читтә яшәүче туганнарыгыздан әйбәт хәбәрләр ишетелер. Атна урталарында бер вакыйга үзегезне балаларча сөендерер. Тормыштагы вак-төяктән ләззәтләнү мөмкинлеге дә пәйда булыр.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Дөнья яңалыклары бернигадәр алҗытыр. Сөеклегезнең ягымлы карашы һәм җылы сүзләре күңелегездәге авыррак хисләрдән котылырга ярдәм итәр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Көтмәгәндә генә кесәгезгә челтерәп акча коелачак. Күңелегезгә бик тә хуш килеп, бөтен борчуларыгызны онытырачак бу. Атна ахырында эшегез искитмәле дәрәҗәдә җайлы барачак.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Мал-мөлкәтне рәсмиләштерүгә бәйле бик зур бер бурычыгыз үтәлер. Бу хәл күңелегездәге барлык борчу-шикләрне гүя юып төшерер. Сәламәтлегезгә бәйле дулкынлануlar да, ниһаять, узганда калыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Күңелле вакыйгалар, кемнәр беләндер үзегез өчен файдалы әңгәмәләр көтелә. Авыррак бер мәсьәләдә төртелеп калганда, дустыгызның киңәше бик тә ярап куяр. Атна ахырында уйландырырлык бер хәбәр ишетелер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бу атнада матур гына бер сюрприз көтегез. Матди хәлнең яхшырып китүенә өметләндерердәй җирлек барлыкка килер. Гомумән, чын күңелдән сөенү өчен сәбәпләр бер-бер артлы чыгып кына торыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Туганнарыгыз сезнең ярдәмгә өметләнер, әмма мөмкинлекләрегезнең чикләнгәнрәк булуы гына... Хәер, озакламый бу хәлдән дә чыгу юлы табылыр. Атна ахырында эшегездә гомуми күтәренкелеккә китерердәй хәлләр көтелә.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бик уңышлы чор. Гади генә бер сөйләшү яки тәкъдим үзегез өчен яңа мөмкинлекләр ачар. Алар гаиләгездәге, сәламәтлегездәге проблемалардан котылуга ярдәм итәр һәм тормышыгызга башка өстенлекләр китерер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Бәхәсләшмәгез: уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Гомумән, бу атнада авызыгызны белеп кенә ачарга кирәк булыр. Сәбәбе? Уңышлыгыздан көнләшеп, кара көеп йөрүчеләрнең тырнак астыннан кер эзләп маташулары...

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Гаиләгездә тынычлык булсын өчен, бер-береңнең кимчелекләрен күрмәмешкә салышырга туры килер. Шулай гына үзара киеренкелектән котылырга мөмкин булыр. Эш мәсьәләсендә әйбәт кенә үзгәрешләр килеп чыгар.

КОМБИКОРМА, ЗЕРНО
Комбикорм для БРОЙЛЕРА ФИНИШ (от 26 дней)
25 кг – 1070 р/мешок
Комбикорм для БРОЙЛЕРА СТАРТ (0-25 дней)
25 кг – 1350 р/мешок
Полный ассортимент: agroline1.ru
Казань, Техническая, 15.
тел.: +792-704-99-706

Диплом о высшем образовании, выданный на имя **Махмутовой Эльвиры Тагировны** (д/р 06.01.1979 г.) в 2003 году Казанской государственной академией ветеринарной медицины им. Н.Э. Баумана считать недействительным, в связи с утерей.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БАР ДА ТАБАННАН БАШЛАНА

Табан – организмның икенче йөрәге, ди белгечләр. Ни гаҗәп, организмыбызның саулыгы турыдан-туры шуңа бәйле икән. Хәтта йөзебезнең матурлыгы да табанның ни дәрәҗәдә сәламәт булуына бәйле икәнне ачыклаганнар. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасыннан алынган саннарга караганда, бүген Җир шарында яшәүчеләрнең 80 проценттан артыгы табан авыруларыннан интегә. Аларны алдан кисәтеп буламы? Табан авырулары ни сәбәпле яшәрә?

Травматолог-ортопед Евгений БИКТАШЕВ шушы мөһим сорауларга ачыклык кертте.

:: Табаныбызның сәламәт булмавы нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?

– Табанның кеше организмында тоткан урыны әйтеп бетергесез. Терәк-хәрәкәт аппараты нәкъ менә шуннан башлана. Табанның формасы бозылмаган булса, ул яхшы хәрәкәтләнсә, калган барлык органнар да көйле эшләячәк. Хәрәкәтләнгәндә табанга басым тигез төшәргә тиеш. Табан белән бәйле хилафлыклар күзәтелгәндә, кешенең умыртка баганасы кәкрәя (сколиоз), тез, оча һәм бот буыннары туза.

:: Табанда хилафлыклар барлыгын нинди билгеләр буенча чамаларга мөмкин?

– Иң элек көндәлек киеп йөргән аяк киемегезгә игътибар итегез. Ул яхшы ук кыршылган, олтаны эчке яктан тузган булса, шикләнергә җирлек бар. Тик торганда яисә хәрәкәтләнгәндә аяклар тиз ару, кичкә таба сызлау, аякны көзән җыеру да табан авырулары башлануын килү турында кисәтергә мөмкин. Табан һәм тубык шешсә дә игътибарлы булыгыз. Табан авыруыннан интеккән хатын-кыз биек үкчәле туфли дә кия алмый. Шулай ук йөргәндә киемгә пычрак чәчрәү дә табандагы хилафлыкларга бәйле. Бу бер аякка нагрузка икенчесенә караганда күбрәк булу белән аңлатыла.

pixabay.com

:: Соңгы арада табан авырулары ни сәбәпле яшәрә?

– Моңа һаман да шул замана чиренә әверелеп баручы хәрәкәт җитмәү сәбәпче. Көндәлек тормышыбызда физик күнегүләр, спорт һәм гимнастика бик аз урын алып тора. Дөрес аяк киеме кимәү дә табан авыруларына сәбәпче була ала. Болар, үз чиратында, яссы табанлылык та китереп чыгарырга мөмкин.

:: Табанның формасы ни сәбәпле үзгәрә?

– Алда телгә алынган сәбәпләрне әйтергә мөмкин. Табан мускулларын ныгытучы күнегүләр ясамау, хәрәкәт җитмәүдән тыш, бу күренеш нәселдән дә күчә ала. Яссы табанлылыкның беренче билгеләре балачакта ук күренсә, бик яхшы. Ул чакта табанның формасын төзәтеп була әле. Әмма кеше олыгайган саен моны эшләү кыен, хәтта мөмкин дә түгел. Махсус ортопедик, индивидуаль олтырак, гимнастика ярдәмендә аякларның хәлен бераз җиңеләйтеп була.

:: Табанны ныгыту өчен, өй шартларында нинди күнегүләр ясарга кирәк?

– Бу очракта бармак очларында, үкчәдә, табанны эчке яккан авыштырып, бармак очларыннан үкчәгә күчеп йөрү файдалы. Бер сызык буенча төз басып йөрү дә нәтиҗә бирә. Ял иткәндә уклау яки туп тәгәрәтеп утыру да табан мускулларын ныгытырга ярдәм итә (рәсемдә).

:: Күпләр баш бармакка сөяк үсүдән зарлана. Аннан операция ясамыйча гына котылып буламы?

– Андый сөяк табанга басым дөрес төшмәү нәтиҗәсендә пәйда була. Башлангыч стадиядә аннан котылып була әле. Бу очракта махсус гимнастика, дөрес сайланган аяк киеме, ортопедик олтырак ярдәмгә килә. Әмма эш болардан узган булса, операция ясамыйча булмый.

Табан авыруларын булдырмау кагыйдәләре

➤Табанның сәламәтлеген балачактан ук кайгыртырга кирәк. Моның өчен бала 3–4 яшьлек чагында ук гимнастика ясарга тиеш.

➤Ортопедик келәмдә йөрү, аяк бармаклары белән уенчык җыю, туп тәгәрәтү, ялanaяк йөгерү дә файдалы.

➤Аяк киеме дә дөрес сайланырга тиеш. Ул артык каты булмасын. Шуңа күрә аны иң элек бөген карарга кирәк. Аның бармак очлары үкчәгә кадәр тиярgә тиеш. Аяк киеменең һава йөртә торган булуы да шарт.

➤Гүзәл затларга исә үкчәсе 5 сантиметрдан биек булмаган, кысып тормаган туфли кияргә киңәш ителә.

➤Табанны сәламәт килеш саклау өчен, ел саен ортопедка күренеп торырга кирәк.



Кишер суы файдалы

Кишер бөтен организмны нормаль хәлгә китерә. Кишер суы B, C, Д, E, K витаминнарына бай, анда организмга аеруча күзләргә гаять файдалы A витамины күп.

Кишер суындагы матдәләр күзнең күрү сәләтен яхшырта. Шуңа күрә аны очучыларга, машина йөртүчеләргә, журналистларга һ.б. эчәргә кушалар.

Кишер суы төрле шешләрдән (яман шештән дә) әйбәт ярдәм итә. Тән тиресе коры булганда, гомумән, тире авыруларын дәвалаганда, ул бик файдалы. Кишер суы эндокрин системаны дәвалый, аны ирләргә җенси көчсезлектән, хатыннарга балага уза алмаганда кулланырга киңәш ителә.

Кишер суы аппетитны күтәрә, ашказаны-эчәк системасы эшчәнлеген, тешләр структурасын яхшырта. Йөкле хатын соңгы айларында көненә 300 мл кишер суы эчсә, бала тудырганда сепсис (кан агулану) булмый. Кишер суы эчкән хатынның сөте сыйфатлы була. Шунлыктан йөкле һәм имчәк баласы булган хатыннарга кишер суы эчәргә киңәш ителә.

Киңәш-табыш

Күзләр яхшы күрсен өчен

Күрәгәнең сәламәтлек өчен шифасы бихисап. Баксаң, ул күзләребезнең яхшы күрүе өчен дә җаваплы икән. Бу максатта аны түбәндәгечә кулланырга киңәш ителә. 100 грамм күрәгәгә өсте капланырлык итеп кенә яңа кайнап чыккан су салабыз да 1 сәгать дәвамында төнәтәбез. Шуннан, күрәгәне ваклап турап, аңа вак итеп уылган кишер һәм 1 аш кашыгы шикәр комы салып, яхшылап болгатабыз. Бу – бер көнлек порция. Әлеге катнашманы елына ике тапкыр, берәр ай дәвамында ашарга киңәш ителә.

Белеп тор!

КОЯШ ШИКӘР ЧИРЕННӘН САКЛЫЙ

Кояш нурлары шикәр чирен булдырмый. Финляндия галимнәре, күпсанлы тикшерүләр үткәреп, шундый нәтиҗәгә килгән. «Кояшлы көннәрдә табигать кочагында еш булган кешеләрнең 80 проценттан артыгын шикәр чире читләп уза», – ди алар. Галимнәр әйтүенчә, кояш нурларыннан качып йөрүче кешеләрнең 60 процентында диярлек шикәр диабетының башлангыч чоры ачыклана.

ИРТӘНГЕ АШТАН БАШ ТАРТСАҢ...

Табиб-эндокринолог, нутрициолог, диетолог Алексей Калинчев фикеренчә, иртәнге аштан баш тарту куркыныч. Иртәнге аштан баш тарту яисә ашау арасында зур тәнәфесләр булу ашказаны-эчәк тракты авырулары кискенләшүенә китерә, дип кисәтә ул. «Кешеләр нишләптер гастрит барлыкка килүгә аптырый. Ә бит алар 5–6 ел дәвамында иртәнге аш ашамыйлар, ач килеш кофе эчәләр, тәмәке тарталар һәм моны гадәти хәл кебек кабул итәләр. Гел шулай яшәдек бит, нишләп чирләдек соң, дип хәйран калалар», – ди Калинчев.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ТАП ТА, ТУЗАН ДА КҮТӘРСЕН

Хатын-кыз 18 ел гомерен аш бүлмәсендә уздыра. Күптән түгел Америка галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Шул рәвешле гүзәл зат көненә уртача 6 сәгать вакытын аш бүлмәсендә уздыра булып чыга. Монда ашарга пешерү белән бергә тәм, ашау, савыт-саба юу, аш бүлмәсен җыештыру өчен киткән вакыт та кергән. Аш-су бүлмәсендәге гарнитур дөрес сайланган булса, бу эшләрне күпкә тиз һәм җайлырак башкарып була дип ышандыра белгечләр. Моның өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Җиһаз ясау компаниясе җитәкчесе Рөстәм САБИРОВтан аш бүлмәсенә гарнитур сайлау серләрен белештек.

pixabay.com

✓ **ТӨЗЕЛЕШЕ.** Аш бүлмәсендәге гарнитурда һәр нәрсә дөрес итеп урнаштырылган булырга тиеш. Ашарга әзерләү кайдан башлана? Дөрес, суыткычтан. Аннан үзеңә кирәкле азык-төлекне аласың да юасың. Шуңа күрә савыт-саба юу урынын суыткыч белән янәшә куярга кирәк. Аннары ул азык-төлекне турыйбыз. Шуңа күрә югычтан соң эш зонасы урнашырга тиеш. Аннары инде плитә урнашса хәерле. Аш бүлмәсе төптән уйлап, һәр нәрсә уңайлы итеп урнаштырылган, тесләре дөрес сайланган булса, анда пычраклык сизелми дә.

✓ **ТӨСЕ.** Кешенең күзе теләсә нинди төскә күнегә. Әмма аш бүлмәсе өчен кер күтәрә торган төсләр әйбәт. Шуңа күрә аш бүлмәсе өчен төп төс итеп ак төсне алырга кирәк. Бу иң еш пычрана торган алгы ягы (фасад) һәм өстәл тактасы (столешница) өлешләренә кагыла. Анда пычрак күренми. Ул бүлмәне дә зуррак, иркенрәк итеп күрсәтә. Кухня гарнитуры өчен төп төс итеп соры һәм кара төсләр сайланган очракта, киресенчә, пычрак 2 метрдан ук күзгә ташланып торачак. Шул рәвешле ашарга пешергән саен юып, чистартып торырга туры киләчәк. Аш бүлмәсендәге гарнитурда ике төс белән уйнау яхшырак. Шуңа күрә анда урнашачак көнкүреш техникасының кара төстәгесен алсаң яхшы.

✓ **ӨСЛЕГЕ.** Ялтырап торган өслекле материалдан эшләнгән аш-су гарнитуры бүген бик зәвыксыз санала. Шуңа күрә ялтыравыксыз өслеккә өстенлек бирергә кирәк. Аны чистарту да җайлырак, тап та сизелми. Ялтыравыклы өслекне исә ашарга пешергән саен кат-кат чистартып, юып торырга кирәк.

✓ **МАТЕРИАЛЫ.** Монда бар да кесә калынлыгыннан тора. Аш-су бүлмәсенә гарнитур ясаганда кулланылган иң кыйммәтле материал – керамика. Софтач (инглиз теленнән – «җиңелчә кагылу» дип тәрҗемә ителә) һәм феникс дип исемләнгән пластик материаллар да яхшылардан санала. Алар бик матур, зәвыклы күренә. Аларда тап та калмый. Күп кенә җитештерүчеләр шушы пластик материалларны сатып ала да аны МДФ материалга ябыштыра. Болай эшләгәндә ул арзангарак төшә, билгеле. Әмма сыйфаты бөтенләй башка була. Ул тора-бара кубачак. Ялтырап торган акрил өслекле материаллар уртача бәягә төшә. Дөрес, алардан ясалган гарнитурның мәшәкате күбрәк – гел чистартып торасы булачак. Пленка белән капланган МДФ материал аш-су бүлмәсенә гарнитур ясаганда кулланыла торган иң очсыз материал санала. Әмма аны чистарту читен, кубып та тилмертәчәк. Гомумән, хәзерге гарнитурларны күбрәк МДФтан, корпус өлешләре ДСПдан эшләнә. МДФны теләсә кайсы материал белән тышлап була. Аның ныклыгы да, бәясе дә шуңа бәйле.

Экономияләргә ярамый?

Аш-су бүлмәсенә гарнитур сайлаганда нәрсәдә экономияләргә ярамый дигәндә, иң элек кешенең аны алганда нинди максатны күздә тотуын ачыкларга кирәк. Аны көн дә ашарга әзерләгәндә уңайлы булсын дип сайлаган кешеләр бар. Гарнитурны аш-су бүлмәсе буш тормасын өчен дип кенә алып куючылар да бар. Соңгылары – нигездә, көн буе эштә булып, өйдә бөтенләй диярлек ашарга пешермәгән, балалары булмаган яшьләр. Аннары гарнитур алганда фурнитура һәм «дымлы зона»га акча кызганырга ярамый. Билгеле булганча, андагы ачылган, ябылган, тартылган һәр нәрсә – фурнитура. Барысы да бер үк төрле эшләгәч, аңа артык акча чыгарып торудан ни мәгънә дип уйлаучылар ялгыша. Фурнитураның кыйммәтләрәге сыйфаты буенча яхшырак. Алар, ким дигәндә, 20 ел хезмәт итәчәк. Аш бүлмәсендә күп вакыт савыт-саба юа торган җирдә уза. Шуңа күрә «дымлы зона»га кергән – смеситель, савыт-саба юу, кашыклар куя торган урыннарга акча кызганмау хәерле.

✓ **ӨСТӘЛ ТАКТАСЫ** (столешница). Аны, иң беренче чиратта, уңайлылыгы буенча сайлау хәерле. Иң очсыз өстәл тактасы пластик материалдан ясала. Дөрес, яньчелгән урын булса, анда су үтәчәк. Кайнар әйбер куйган урыннарда төсе үзгәреп китәргә дә мөмкин. Аш-су бүлмәсендәге гарнитур тәрәзә турысыннан узган очракта пластик өстәл тактасы куярга ярамый. Ник дигәндә, ул, дым тартып, күгәреп утырачак. Агач столешница табигый материалдан эшләнә. Шуңа күрә кыйммәткә дә төшә. Табигый материалдан эшләнгән мондый өстәл тактасы әллә ни озак хезмәт итмәячәк. Тора-бара аның өстендәге лак бетәчәк, ул урын агарачак. Ясалма материалдан эшләнгән акрил өстәл тактасы матурлык өчен генә ярый. Аны ясаганда сумала күп, таш аз кулланыла. Ул бик тиз кыршыла. Аның бердәнбер уңай ягы бар. Ул да булса, аннан төрле формадагы өстәл тактасы ясап була.

Өстәл тактасы ясаганда кулланылган ясалма материалның киң таралган тагын бер төре – кварц. Монда, киресенчә, тоташтыручы каты таш бик күп, сумала аз кулланыла. Матурлык белән мактана алмаса да, практик яктан бик отышлы бу вариант. Анда курыкмыйча кайнар әйбер дә куя аласың. Төсе дә үзгәрми, тап та күренми. Табигый материал саналган мәрмәр һәм граниттан эшләнгән өстәл тактасы да бар. Беренчесен алып та торасы юк. Ул майны, тапны – барысын да сеңдерә. Гранит исә, киресенчә, аларның берсен дә сеңдерми, тап та күрсәтми. Без табигый әйбер кыйммәт була дип уйларга күнеккән. Монда, киресенчә, өстәл тактасы никадәр уңайлырак, тизрәк чистарса, шулкадәр яхшырак. Бәясе дә шуңа карап үзгәрә.

✓ **НИНДИ ПЛИТӘ САЙЛАРГА?** Сатып алучылар ике төргә бүленә. Берәүләр өчен ризыкның тиз пешүе кирәк. Андыйлар гадәттә индукцияле плитәгә өстенлек бирә. Әмма аның тискәре ягы да бар. Беренчедән, мондый төр плитәдә пешерү өчен махсус савыт-саба алырга кирәк булачак. Бу – өстәмә чыгым дигән сүз. Анда электр энергиясе дә күбрәк тотыла. Әмма электр белән эшләүче плитәнең өслеге шома булганлыктан, аны чистартырга уңайлы. Газ плитәсенең чыгып торган конфоркаларын юу күпкә мәшәкатьлерәк. Өстәвенә газ плитәсе кислородны яндыра. Шуңа күрә анда ашарга пешергәндә аш бүлмәсендә һава бетә.

Аш булсын!

Тавык тәмле булсын, дисәң

Тавык ите аеруча тәмле булып кызсын дисәң, аңа шикәр (!) дә өстәргә кирәк. Ризыкның тәмлелеге анда тозлы, баллы, ачы тәмнәрнең берьюлы булуына бәйле. Шуңа күрә ит ризыклары әзерләгәндә дә шикәр салырга киңәш ителә. Кыздырылган тавыкка аеруча килешә ул. Аз гына суга бер үк күләмдә тоз һәм шикәр салып болгатыгыз. Соңрак шуны кыздырасы тавык кисәкләренә бөркеп, яраткан тәмләткечләрегезне сибегез.

Киңәш-табыш

▶ Ипи искермәсен өчен ул салынган савыт читенә чи бәрәңге, алма куегыз, йә булмаса чеметеп кенә тоз сибегез.

▶ Балык яки ит кыздырганнан соң бөтен өйгә таралган авыр истән серкә (уксус) коткарачак. Моның өчен табага ике аш кашыгы серкә салып, шуны парга әйләнеп беткәнче кайнатырга кирәк.

▶ Духовкага ябышкан май һәм көйгән тапларны бетерү өчен, кичтән аның якларына нашатырь спирты тидереп чыгыгыз. Иртән аны чиста чүпрәк белән сөртеп кенә аласы булачак.

▶ Иске термостан килгән авыр исне бетерим дисәң, эченә ике аш кашыгы дөге, өстенә бер стакан су салып куегыз. Берничә сәгатьтән соң дөгене ташлап, термосны яхшылап юыгыз.

▶ Калай табадагы (противень) көйгән урыннарны чистарту өчен 1әр аш кашыгы серкә белән водород перекисе кушылган катнашма әзерләргә кирәк. Аны табага сөртеп, 10 минут тотасы. Соңрак агып торган суда яхшылап юып, чиста сөлге белән корытыгыз.

Бакчачыга

РОЗАНЫ ТАМЫРЛАНДЫРУ ЫСУЛЫ

Бер чәй кашыгы бал, ике чәй кашыгы алоэ согы (сабакны бер тәүлек суыткычта тотсагыз, согы күбрәк чыга), бер чәй кашыгы көлгә ярты стакан су салыгыз. Роза сабакларын ярты көнгә шул суга утыртып торыгыз. Тиешле вакыт үткәч, туфракка утыртыгыз. Онытмагыз: даими җиргә күчереп утыртканда аның 2–3 саламәт бөресе булырга тиеш. Өстен пластик шешә яки полиэтилен пакет белән каплап, җылы урынга куегыз. Вакыт-вакыт өстен ачып, чылатып алырга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ҖОМГА КӨННЕ ДӘ, КОЯШ БАЕГАЧ ТА РӨХСӘТ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Чисталык – иманның яртысы», – дигән. Мөселман кешесе тәне белән генә түгел, җаны белән дә чиста булырга омтыла. Үзебезне генә түгел, әйләнә-тирәбезне дә чисталыкта, пакьлектә тотарга тырышабыз без. Бик тиздән һәр йортта өй юулар башланачак. Бу йола пәйгамбәребез яшәгән чорда да булганмы? Ислам динендә өй җыештыру, өй юуның билгеле бер тәртибе бармы?

«Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән әнә шул хакта сөйләштек.

Дамир Бәдриев

:: Ислам дине чисталык, пакьлек кебек төшенчәләргә ничек карый? Бу хакта хәдисләрдә ниләр әйтелә?

– Чисталык динебездә мөһим урын алып тора. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга биш вакыт намазны фарыз кылган. Ул һәр намаз алдыннан чистарынырга – тәһарәт алырга кушкан. Шул рәвешле кеше көненә ким дигәндә биш тапкыр чистарына булып чыга. Шуның буенча гына да мөселман кешесе өчен чиста, пакь булуның ни дәрәҗәдә әһәмиятле әйбер икәнлеген аңлап була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Чисталык – ярты иман ул», – ди. Иманының дәрәҗәсен тышкы кыяфәтеннән дә күреп була. Тышкы яктан чиста булган кешенең күңеле дә чиста була. Моннан тыш кешенең җаны да чиста, пакь булырга тиеш. Пәйгамбәребез, сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп: «Әгәр сезнең өй алдыннан елга агып торса һәм сез шул елгада биш тапкыр юынсагыз, сезнең тәнегездә пычрак җир калыр идеме?» – дип сораган. Сәхабәләр: «Юк», – дип җавап биргән. Шуннан пәйгамбәребез: «Намаз да менә шушы елга кебек сезнең гөнаһларыгызны юа», – ди. Шул рәвешле тәнне чистартыр өчен мөселманнар су белән юынсалар, йөрәкләрен пакьләр өчен биш вакыт намаз укый.

:: Яз җиту белән өй юулар башлана. Бу йола пәйгамбәребез яшәгән чорда да булганмы?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм яшәгән чорда өйләр бездәге кебек түбәле түгел, диварлы гына булган. Өсте ачык калган, бер бүлмәдә сөйләшкән тавышлар икенчесенә ишетелеп торган. Анда өйләр бер-берсенә терәлеп торган, бездәге кебек күршеләр белән бераз ара калдырып яшәмәгәннәр. Пәйгамбәребез дә абыйсы Әбу-Ләһәб белән дивар аша гына күрше булып яшәгән. Ул аның динне таратуына каршы була, аңа дошманлык итә башлый. Пәйгамбәребез намаз укыган вакытта абыйсы аның ягына чүпләр, пычрак ыргыта торган булган. Ул чордагы чисталык мәсьәләсен өлешчә әнә шуннан чамаларга мөмкин. Динебездә өй юу буенча ниндидер тарихи мәгълүмат юк. Кеше үзенә йола итеп алган билгеле бер тәртип кенә бу.

:: Өйне ишек төбеннән түгел, түр башыннан юа башларга кирәк, диләр. Бу нәрсәгә бәйле? Ислам динендә өй юу, җыештыруның билгеле бер тәртибе бармы?

– Өй юуны түр башыннан башларгамы, әллә ишек ягыннанмы – моның дини әһәмияте юк. Бу күбрәк халыкның үзе уйлап чыгарган ышануы, гадәте булып тора. Чынлыкта, ислам динендә мондый таләп тә, өй җыештыруның билгеле бер тәртибе дә юк. Иң мөһиме – чисталык булсын.

:: Җомга көнне өй җыештырырга ярыймы? Ә гает көнне рөхсәт ителәме?

– Рөхсәт ителә, әлбәттә. Җомга намазына барыр алдыннан мөселманнар өчен тәһарәт алу гына түгел, тулысынча госел алу да хәерле гамәл булып тора. Мөселман кеше җомгада гына түгел, көн саен намаз укый. Ул намаз укыган урынын һәрчак чиста тотарга тиеш. Шуңа күрә җомгада гына түгел, һәр көнне өй җыештырырга кирәк. Гает көнне өй җыештырырга ярамый дигән чикләү дә юк. Дөрес, моны бу көнгә калдырмасаң да була. Җомга, гает көннәренә кадәр өйне җыештырып, пакьләп куйсаң, шушы бәйрәм көннәрендә намаз уку, гыйбадәт кылу кебек изге эшләргә вакыт күбрәк калачак.

:: Кояш баегач, идән юган суны ташларга ярамый, диләр.

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кояш баткан вакытта балаларыгызны яныгызда тотыгыз. Бу вакытта җирдә шайтаннар таралә», – дигән. Ләкин ниндидер су түгү яки башка эшләргә карата диндә башка андый тыю, боерык юк. Шуңа күрә халык телендә андый ышанулар булырга мөмкин. Әмма мөселман кеше, иң беренче чиратта, бу хакта ислам динендә ниләр әйтелгәненә ачыкларга, бары шуңа гына таянырга тиеш.

:: Кояш баегач, тузан сөртергә, өй җыештырырга ярыймы?

– Көн буе эштә булгач, күп кешенең өй җыештырырга да вакыты калмый. Шуңа күрә бу эш еш кына кичкә кала. Халык телендә, дөрестән дә: «Кояш баегач, өй җыештырырга, тузан сөртергә ярамый», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Әмма ислам динендә андый тыю юк. Димәк, аны эшләргә ярый. Кеше үзенең тормышын авырайтмаска тиеш.

:: Өй җыештырганда, җомга вакыты дип, эшне туктатып торабыз. Болай эшләү мәҗбүриме?

– Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Йә, иман китергән бәндәләр, кайчан җомга намазына чакыралар, үзегезнең сату-алу эшләрен калдырыгыз һәм Аллаһны зикер итүгә ашыгыгыз. Бу сезнең өчен хәерле булачак», – ди. Шул рәвешле, җомга намазы җитеп, азан яңгырауга, мөселман, бөтен эшләрен калдырып, намазга ашыгырга тиеш. Бу – Аллаһы Тәгаләнең боерыгы. Әлеге таләп шул ук өй җыештыруга да кагыла. Мөселман илләрендә дә, азан яңгырау белән, зур базарларда мөселманнар күбесе кибетләрен бикләп тә тормыйлар, шул килеш кенә калдыралар да мәчеткә намазга китәләр. Беркем дә шушы вакытта андагы бернәрсәгә дә тими, урлашмый, җинаять кылмый. Намазны укыгач, кире үз эш урыннарына кайтып, сату-алу эшләрен дәвам иттерәләр.

Ураза көндәлеге



Сорауларга «Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН җавап бирә.

Сез сораган идегез...

◆Ураза тотканда авызны ялгыш тиешле вакыттан бер-ике минут алданрак яки соңрак ачсаң, ни була?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм: «Вакыт кергәч, кояш баегач, уразагызны өзегез һәм ашыгыгыз», – дигән. Әмма ураза тотканда авызны ялгыш бер-ике минутка алданрак ачуның бернинди зыяны да юк. Ул зур хата булмаска тиеш, чөнки бу шулкадәр зур вакыт түгел. Ләкин авызны биш-ун минут алдарак ачсаң, ураза бозылачак. Рамазан аеннан соң ул көн өчен яңадан бер көн ураза тотарга туры киләчәк. Авызны соңрак ачуның исә бер куркынычы да юк. Азан әйткәч кенә авыз ачкан кешеләр дә бар.

◆Косу уразаны бозамы?

– Әгәр кеше моны белеп эшләсә, ягъни авызына бармак тыгу яки башка юл белән косыгын чыгарса, ул вакытта аның уразасы бозыла. Әгәр ул мәҗбүри рәвештә түгел, кисәк кенә, табигый рәвештә косып җибәрсә, уразасы бозылмый. Кеше күбрәк ашап җибәрсә, аның ризыгы авызга кадәр күтәрелергә мөмкин. Әгәр аның ризыгы авызга кадәр күтәрелсә, телгә хәтле ирешсә, ягъни авызын тутырса һәм ул аны кире йотса, бу очракта уразасы бозыла.

◆Ураза тотканда казага калган көннәрне гаеттән соң ничә көн узгач тота башларга мөмкин?

– Казабызны гаетнең икенче көнендә кайтарырга мөмкин. Ник дигәндә, Ураза гаете фәкать бер көнгә генә сузыла. Икенче көнне исә шәүвәл аеның сөннәт уразасы керә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм аның турында: «Кеше шәүвәл аеның беренче атнасында, ягъни алты көн ураза тотса, ул ел буена ураза тоткан әҗер-савапка ирешә», – дигән.

Хәдис

Әбу Һурайра тапшыруынча. Пәйгамбәр: «Ураза ул – җәһәннәм утыннан коткаручы пәрдә, ураза тоткан кеше начар сүз сөйләмәсен һәм наданнарга охшамасын. Кем дә булса аның белән талашырга теләсә яки аны ачулана башласа, ул ике тапкыр: «Мин ураза тотам!» – дип әйтсен. Мин җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм: ураза тота торган кешенең авызыннан килгән ис Аллаһы Тәгалә өчен мускусның хуш исеннән дә тәмлерәк, һәм Ул: «Ул Минем өчен ризыктан, эчемлектән һәм үзенең дәртеннән баш тарта, бу уразаны ул Минем өчен тота һәм Мин аңа моның өчен әҗерен бирәчәкмен. Ә яхшы эшнең әҗере ун тапкыр артыграк булачак!» – дип әйтер», – дигән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

МӨНИР РАХМАЕВ: «ГАИЛӘ КОРУ КЕШЕНЕ БӨТЕНЛӘЕ БЕЛӘН ҮЗГӘРТӘ»

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсендә кунакта танылган җырчы, алып баручы Мөнир РАХМАЕВ. Нинди яңалыклары бар аның? Өйләнү Мөниргә килешкәнме? Эстрададан китәргә җыенмыймы? Без шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Хәлләр яхшы. Рамазан аена аяк басу белән, сәламәтлегемне кайгыртырга башладым. Әле менә күптән түгел операция кичердем. Тагын берничә тикшерену узарга ниятлим. Кыскасы, бу айдан тулысынча сәламәт, нык булып чыгасым килә. 33 ел буе сәламәтлегемә игътибар итмәдем, үземне карамадым. Эш күп, вакыт юк, дип кичектердем. Вакыты җитте менә.

:: Сез татар эстрадасыннан бөтенләй читләштегез төсле.

– Эстрададан бөтенләй киттем, дип әйтә алмыйм. Бу – үзенә күрә бер паузадыр. Сирәк булса да, концертларда да чыгыш ясыйм, гастрольләрдә дә булгалыйм. Үзем концертлар куймыйм һәм якын киләчәктә куярга җыенмыйм да, түгелгән көчең үзен акламый. Ә дәшкән җирдә җырлап китәм.

:: Тагын ниләр белән шөгыльләнәсез? Бизнес өлкәсендә дә проектларыгыз бар, ахры.

– Иҗаттан да читләшмәдем, бизнеста да юнәлешләрем шактый күп. Әле менә тиздән хатыныма «Матурлык салоны» ачарга телим. Моннан тыш, төрле мәҗлесләр алып барам. Мәскәүгә барып, «Стендап мәктәп»тә укып кайттым, иҗатның яңа юнәлешен үзләштерәм. Мөмкинлек булганда, күңел кушканда, иҗатны да ташламаска иде. Гомумән, ир кеше үзенә дә, гаиләсенә дә матур тормыш бүләк итәр өчен тырышырга тиеш.

:: 10 ел элекке Мөнир белән бүгенге Мөнир арасында нинди аермалар бар?

– Өйләнү кешене бөтенләе белән үзгәртә. Бүген минем өстенлекләрем башка, үзем өчен генә түгел, гаиләм, якыннарым өчен дә тырышам. Ләкин мин нәкъ элеккечә алга омтылам, үрләр яуларга тырышам. Энергия – шул ук.

:: Сез – усал әтиме, гаиләгезне ишәйтү уе бармы?

– Мин – таләпчән әти. Билгеле, баламны мин бик яратам. Ләкин гел уч төбендә йөртүне дөрес тәрбия дип санамыйм. Илсөяр йомшак ул яктан, ә мин катырак та әйтеп куярга мөмкинмен. Ким дигәндә өч-дүрт бала үстерәсебез килә.

:: Илсөярне башта тамашачыларыгыз яратып бетермәде кебек.

Зәйтүнә Мәүлүдова 1893 елда Чистайда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Әтисе Хәйдәр бик яшьли вафат була. Шуңа күрә биш бала, төрле һөнәрләр үзләштереп, эшләп көн күрәләр. Әниләре Зәйтүнәне җәдит мәктәбендә укыта. Гаиләдә китап укырга яраталар, газета-журналлар алдыралар. Кыз балачактан ук Чистайның иң зыялы кешесе саналган Мөхәммәтзакир Камалов гаиләсе белән аралаша. Фатих Әмирхан белән дә туганлык җепләре була. Шуңа күрә кызның укымышлы, үткен, аралашучан булуы гаҗәп түгел.

1907 елда Зәйтүнә гаиләсе белән Казанга күчеп килә һәм рус-татар мәктәбендә укый башлый. 15 яшьлек кыз Тукай шигырьләренә гашыйк була.

Очрашулар

Мирсәй Гарифның «Мәңгелек мәхәббәт» китабында ике яшь йөрәкнең очрашулары турында Зәйтүнәнең мондый истәлекләре язылган.

«1908 елның март башларында булса кирәк, хәзерге Тукай белән Татарстан урамнары почмагында яшәүче танышларыбызга барышлый, безгә апам белән редакция яныннан үтеп китәргә туры килде. Тәрәзә ачык, Фатих абый Әмирханов тәрәзә янында утыра. Аның белән исәнләшкәч, ул: «Кая барасыз, озак тормагыз, тиздән монда Тукай киләчәк», – диде. Кызлар киләләр... «Тукай күрешкәндә безгә бер генә караш ташлады, – дип дәвам итә Зәйтүнә, – аннан кулларыбызга текәлеп кенә: «Исәнсау йөрисезме?» – дип куйды. Бу минем Габдулла Тукаев белән беренче тапкыр очрашуым булды».

Кызлар белән очрашканнан соң Габдулла бик тә канәгать булып, дәртләнеп китә. Бу вакытта иҗатында мәхәббәт лирикасы шактый урын ала.

Соңрак Зәйтүнәнең улы, язучы Атилла Расих та «Ишан оныгы» исемле китабында әнисе сөйләгән истәлекләрне яза.

« ...Ул арада Тукай үзе дә килеп җитте. Безнең белән гадәтенчә кыяр-кыймас кына исәнләште. Мин, аның янына барып, кул биреп күрештем. Һәмниләр эшләп йөрүен төпченә башладым. Ул исә әдәби кичәләр оештырып йөрүләрен, шунда хор өчен кирәкле материаллар әзерләвен әйтте. «Сез килерсезме?» – диде. Үзе сөйләшкәндә түбәнгә карый, миңа йөзенә карамаганда гына күз ташлый. Һәм дә тизрәк китәргә ашкына. Мин аның кулыннан тоткан килеш байтак вакыт сөйләшеп тордым. Бәлки, аның сөйләшәсе килмидер, бәлки, кеше-кара күрүеннән хурланадыр диеп уйладым...

Габдулла Тукай белән без тагын әдәбият кичәсендә күрештек. Тукай үзенең «Утырышу» шигырен укыды... Антракт булды. Мин тиз генә конфетти барып алдым да сәхнәдән чыгуларын көтеп тордым. Алдан Тукай килеп

чыкты. Кулымдагы конфеттины аңа сиптем... Кулын кысып, тәбрик итә башладым. Аннан бераз кырыйгарак китеп сөйләшә башладык... Кайтканда бергә кайтырбыз бит, дидем. Тукай ризалык белдерде. Кичә тәмам булды. Мин, нихәтле эзләсәм дә, Тукайны таба алмадым...»

«Әнием, бу кичәдән кайткач, Тукайның үзенә карата мөнәсәбәте турында шик-шөбһәләргә бирелә», – дип яза Атилла Расих.

Соңгы күрешү

Казандагы тормышның авырлыгы Чистайга кайтырга кирәк дигән фикергә китерә. Кызлар соңгы тапкыр «Әл-ислах» редакциясенә баралар. Бәхеткә, Тукай редакциягә килгән чак була... «Бергәләп урамга чыктык. Китәчәгебезне ишеткәч, шагыйрь башын аска иеп, бик жәл, диде», – дип язып калдыра Зәйтүнә бу очрашу хакында. Кызлар шагыйрьгә хат язып торырга булалар, адресын сорыйлар. Габдулла аларны озатырга төшәргә, шунда адресын бирергә вәгъдә итә. Бу Зәйтүнәнең яраткан шагыйрен соңгы тапкыр күрүе була. Чөнки Тукай бу юлы да сүзендә тормый. Пристаньда никадәр өметләнеп көтмәсен, ул күренми...

Тукайдан хәбәрләр

...Чистайга кайтып, бераз вакыт үткәч, бер газетада «Кызык гыйшык» дигән шигырь басыла. Зәйтүнә ул вакытта шигырьнең үзенә карата язылганлыгын башына да китерми. Тукайның аңа булган мәхәббәте кайнар һәм сәер, яшерен була.

Август аенда Казаннан Чистайга «Сәйяр» труппасы килә. Шунда Тукай труппа башлыгы Габдулла Кариевка бер әманәт тапшыра. «Чистайда минем ике таныш кызым бар, шуларга контрамаркалар җибәрәм», – ди. Зәйтүнә бер туганы белән спектакльгә бара. 1910 елда Кариев труппасы яңадан Чистайга килә. «Тукайдан сезгә күп сәлам. Ул да Чистайга килергә булып калды әле», – дип, кызны тагын өметләндерә. Тукайның, Зәйтүнәгә багышлап, кырыктан артык шигырь язганлыгын әйтә. Соңрак Фатих Әмирхан да бер хатының кырыена, Тукай да сезне бик сагына, дип язып куйган була. Әмма бу сүзләр кызның ачуын гына китерә.

ФАТИХ ӘМИРХАН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН:

«Әле дә булса хәтеремдә: мин Тукайга үзе мәхәббәт итә торган бер кыздан (Зәйтүнә Мәүлүдова турында сүз бара) качып йөрүенең сәбәбен аңламаганымны... сөйләдем. Ул озак җавап бирми торганнан соң, үзенең бер күзен ишарә белән күрсәтеп:

– Печать проклятия! – диде. Шул вакытта мин аның карашында, тавышының аһәңендә авыр бер фаҗигави өметсезлек сиздем. Шуннан соң ул сул күзенең ни өчен итеп болай ак төшерелеп калдырылган икәнен сөйләп китте...»

Язмыш

Шулай итеп, башкача очрашу мөмкин булмый. Тормыш кызны бөтереп кенә ала. Ул Югары Курса имамында укый. Кызлар мәктәбендә укыта. Аннан әниләре аны Буби авылына, мөгаллимнәр әзерли торган мәктәпкә илтеп куя. Зәйтүнә анда таныклык алырга чак өлгерә. 1911 елда Буби мәдрәсәсенең мөгаллимнәрен кулга алалар, шәкертләрне куалар. Зәйтүнә кире Чистайга кайта, рус телен өйрәнә башлый. Тамак туйдырыр өчен тегү-чигү эшләре белән шөгыльләнә. Озак эзләнгәннән соң, хәзерге Башкортстанның Туймазы районы Каран-Бишенде авылына мөгаллимә булып урнаша.

1913 елның апрелендә Габдулла Тукай вафат була. «Тукай үлгәнне ишеткәч, бик еладым. Әкрен генә йөткерә башладым. Ябыктым. Әни мине, профессорга күрен дип, Казанга җибәрде. Иң элек зиратка чаптым. Тукай кабере – кергәч тә капканың уң ягында. Кабер янында Коръән укып, озак елап утырдым», – дип яза Зәйтүнә истәлекләрендә.

Шуннан соң ул, абыйсы тәкъдим иткәнчә, әнисе белән бөтенләйгә Троицк шәһәренә, туганнары янына чыгып китә. «Сөембикә» исемле кызлар мәктәбендә укыта башлый. Муеннан эшкә чумып, үзенә юаныч таба. Анда яшәгәндә кызга ишан, мәгърифәтче Зәйнулла Рәсүлевнең уртанчы улы Кадыйр гашыйк була. Кияүгә чыгарга да тәкъдим ясый. Зәйтүнә баш тарта. Әмма кызның язмышы өчен борчылган әнисе белән килешеп, тиз арада никах укыталар. Зәйтүнә бу хәлдән соң, харап булдым, беттем, дип аяктан егыла. Истәлекләрендә бу хакта: «Рухи үлем алдым», – дип яза. 1914 елда туй ясыйлар. Бүләк итеп, әтиләре яшьләргә хаҗга бару мөмкинлеге тудыра. Алар юлга чыгарга җыенгач кына, Беренче Бөтендөнья сугышы башлана. Кире уйламыйлар, олы юлга кузгалалар. Кайтырга акча юклыктан, Мәдинә шәһәрендә яшәп калырга мәҗбүр булалар. 1915 елда, бурычка акча җыеп, Истамбулга барып җитәләр. Шул елның сентябрендә Зәйтүнә ир бала таба. Туган илгә 1918 елның мартына гына кайтып җитәләр. Троицкида 1928 елга кадәр яшиләр. Ачлык елларында мәктәпләр эшләми. Зәйтүнә тегү-чигү, ямау-ялгау эшләре белән тамак туйдырырга мәҗбүр була. Казанга кайткач та, укытучылык буенча эш таба алмаячакларына инаналар. Кадыйр, ишан малае булганга, мондый эш турында хәтта хыяллана да алмый. Зәйтүнәгә эшләү мөмкинлеге тудырыр өчен, загска барып, аерылышу турында кәгазь алып кайталар. Ышанычсыз кеше баласы дип, Атилланы да мәктәптән, уку йортларыннан куып чыгарган очраклар күп була.

Зәйтүнә ханым 18 нче татар мәктәбендә укыта. Белемен күтәрү өчен, төрле педагогик курсларда укый. 1957 елда Казанда 64 яшендә вафат була. Татар зиратындагы кабере 64 ел узгач, 2021 елда табыла.

Кабер ташында Тукай шигыреннән өзек урын алган:

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит – чын җүләр түгел диген!

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи?
Ул синең васфеңдә: «Ля шәркыйя, ля гарбия», – ди!

Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып.



ЧИКЛӘНМӘГӘН ЧИКЛЕ МӨМКИНЛЕКЛӘР

Мәктәпләрдә уку елы ахырына якынлаша. Чыгарылыш сыйныф укучыларының да, әти-әниләрнең дә башлары әйләнгән чак. Укырга керергә кирәк! Дөрес, сау-сәламәт балага мөмкинлекләр җитәрлек. Әгәр баланың физик мөмкинлекләре чикле булса... Бу очракта нишләргә? Үзе теләгән җиргә андыйларны кабул итмәсәләр? Татарстанда алар өчен белем алу өчен шартлар бармы? «ВТ» журналисты республикада авыру балаларны һөнәргә өйрәтә торган уку йортлары җитәкчеләре һәм баласын укырга кертергә теләүче әти-әниләр белән аралашты.

Баланы кызганмагыз!

Кукмара районының бер авылында гомер итүче Зөлфия ханым әнә шулай ди. Заманында район табибы аңа алтын киңәшләр бирә: «Балам авыру дип, аны кызганып, эш эшләтмичә, назлап-сыпырып кына утырма! Олы балаларыңны ничек тәрбияләдең, шулай итеп үстер. Авыру дип санама!» Зөлфия ханым шулай эшли дә. Улына кирәк чакта кырыс та, кирәк икән ягымлы да була, вакытында мактый да, тотып сүгә дә.

– Иң элек баламны авыл мәктәбендә укытып карадым. Авыррак булды. Аннары инде коррекция мәктәбенә укырга бирдем. Анда ул 9 сыйныф тәмамлады. Тукталып калмадык, Мамадыштагы политехника көллиятенә укырга керде. Авыру булса да, кулы эшкә өйрәнде. Аның өчен җаным тыныч. Ул кешеләр белән дә аралаша, тормыш итәргә дә өйрәнеп килә, – ди Зөлфия ханым.

Без дә Мамадышта урнашкан көллият җитәкчелеге белән элемтәгә кердек.

– Көллияттә авыру балалар өчен махсус төркем бар. Әгәр укырга керәм дип килүче бар икән, без махсус программа буенча төркем төзибез. Бездә әлеге балалар штукатур-маляр һөнәренә өйрәнәләр, – ди уку йортының директор урынбасары Динар Хәкимов. – Физик мөмкинлеге чикләнгән балалар белән эшләү җиңелрәк тә әле. Алар икенче төрлерәк, сүзне тыңлыйлар, кушканны үтиләр.

Мамадышка укырга килүчеләр арасында ДЦП диагнозлы һәм акылга зәгыйфь балалар да бар. Динар Хәкимов әйтүенчә, алар белән уртак тел табарга гына кирәк икән.

– Бездә балаларны бүлү юк. Барысына да бертигез караш. 2 ел рәттән икешәр төркем укытабыз. Ул балалар үзләренең тырышлыклары белән аерылып тора. Төрле чаклары була, әмма махсус инклюзия буенча укып кайткан педагоглар ул балалар белән уртак телне тиз таба, – ди җитәкче.

Ул әти-әниләргә киңәшен дә бирде:

– Кайчак, бала авыру дип, коррекция мәктәбенә бирергә ашыгалар. Сез аның мөмкинлеген карагыз. Бәлки, балагыз сау-сәламәтләр арасында укый аладыр. Ә бит бу авырулар арасында югары белем алырга тырышучылар да юк түгел. Безнең көллияткә тугызынчы сыйныфны тәмамлап килеп булса, югары уку йорты өчен урта белем алу мәҗбүри. Шуңа да кайбер балалар кичке мәктәпләрдә укып, вузга керә.

> Балагызга һөнәрне дөрес итеп сайлагыз. Кимчелегенә карагыз. Бер танышымның колаклары ишетми, ул компьютерлар буенча укып чыкты. Балагыз тормышка әзер булсын дисәгез, һөнәрле итегез!

Маңгаена язылмаган

Сәламәтлегендә кимчелеге булган балаларны кайчак сауларыннан аерып та булмый, ди Түбән Кама агросәнәгать көллияте директоры Флера Шәйгарданова. Хәзерге вакытта аларда 184 авыру бала белем ала икән. Алар республиканың төрле районнарыннан җыелган. Биредә читтән килгәннәр өчен тулай торак та бар.

Түбән Кама агросәнәгать көллиятендә балаларны слесарь, штукатур, столяр, бакчачы, кондитер, тегүче белгечлекләре буенча укыталар.

– Без республиканың барлык коррекция мәктәпләре белән ныклы элемтәдә торабыз. Безгә бик күп районнардан киләләр. Үз-үзләрен карый алырлык балаларны укырга алабыз. Араларында психик авыру белән интегүчеләр дә күп. Әмма күбесенең инвалидлыгы юк. 184 баланың 60ы гына инвалидлык алган. Ә бит барысының да кимчелеге бар. Ата-ана баласының авыру икәнен кабул итәргә, аның мөмкинлегеннән чыгып, тормышка әзерләп калдырырга тиеш, – ди Флера ханым.

Түбән Кама агросәнәгать көллияте тулай торагында яшәүчеләр дә нәкъ шушылай итеп олы тормышка әзерләнә.

– Бездә укучыларга стипендия түләнә. Алар үз акчаларын үзләре тота. Кешеләр белән аралашырга өйрәнәләр. Әле менә 2 нче курста укучылар практикага китте. Күбесе шунда эшкә дә кала. Максатыбыз – авыру балаларны төрле яклап үстерү. Белем генә бирен калмыйбыз, төрле сәләтләрен дә ачабыз. Алар безгә килгәч, сәхнәгә дә менә, төрле бәйгеләрдә дә катнаша. «Абилимпикс» бәйгесендә сау-сәламәт кешеләр белән бергә катнашып, беренчелекне алган укучылар да бар, – ди Флера Шәйгарданова.

Могҗиза булмады

Казанда яшәүче Ландыш Имамиеваның да улы быел 9 нчы сыйныфны тәмамлый. Баласы ДЦП диагнозы белән туа. Табиблар, балаң урын өстеннән тора алмаячак, диләр. Әмма ана киресен раслый. Кечкенәдән бик актив була. Әнисе аны кая гына йөртми?! Улы аякка да баса, ничек итсә итә, йөрергә өйрәнә. Шөкер, аның акыл үсешенә дә зыян килмәгән. Малайның бер теләге бар: киләчәктә театр артисты буласы килә. Әмма аның мөмкинлекләре белән бу хыял гына булып кала. Бу очракта авыру балаларга нишләргә? Бер Ландышның малае гына түгел, театрга гашыйк балалар күп икән алар. Кәрим Тинчурин театрында нәкъ менә шундый балалар өчен «Могҗиза» дип аталган театр студиясе эшләп килә.

– Театр студиясенә йөри башлагач, бик сөенгән идек. Янәсе, мәктәп бетергәч, улым театр училищесына керер. Тик булмады. Безнеке кебек диагнозлы бала анда укый алмаячак икән. Без Казан театр училищесына да бардык. Барысын да аңлаттылар. Улым өчен түгел бу. Балам өчен өзгәләнеп кайттым. Аның исә укырга керү теләге көчле: директорга, аяклары тыңламаса да, мин бии дә алам, дип тора. Өйгә кайткач: «Минем дә башка балалар кебек йөрәгем бар, күңелем бар», – дип үкседе. Әни буларак, миңа да авыр, – ди Ландыш.

Без тагын берничә әни белән сөйләштек. Барысының да теләкләре бер: балаларын театр артисты итеп күрәселәре килә.

– Кызым Эльвина бик яратып спектакльләрдә катнаша, – ди Алсу Федотова. – Сөйләшүендә кимчелекләр бар, аңарда ДЦП диагнозы. Әмма никадәр генә сөйләшеп, аңлатсам да, уеннан кире кайтмый. Мин театрда эшләячәкмен, дип тора. Инде үгетли торгач, 11 нче сыйныфны тәмамлап, Казан дәүләт мәдәният институтына укырга барырга булды.

Без Казан театр училищесы директоры Руфина Таҗетдинова белән сөйләштек.

– Дөрес, бу балалар театр училищесына документларын тапшыра ала. Әмма укырга кергәндә аларга беренче ташлама да каралмаган. Башкалар белән бер-рәттән барлык биремнәрне дә үтәргә тиеш булалар, – диде директор. – Бездә уку җиңел түгел. Сау-сәламәт балалар да кайчак укуларын ташлап китәләр. Ә монда сүз ДЦП диагнозлы балалар турында бара. Аларга бик авыр булачак. Иҗатны үз итсәләр дә, бу балаларга дөрес итеп аңлатырга кирәк. Алар актер була алмыйлар. Тамакларын туйдыра торган һөнәр сайларга кирәк, ә театр уйнар өчен мөмкинлек җитәрлек. Ниндидер студиядә яки түгәрәкләр оештырып, бу эшне дәвам итәргә була.

> Мине дөрес аңласыннар: физик мөмкинлеге чикләнгән балаларга карата һич тә начар мөнәсәбәттә түгел мин. Әмма һәр һөнәрнең үз таләбе бар. Шуңа да күңелне төшермичә, үзеңне башка өлкәдә табарга кирәк.

Махсус театр кирәк

Кәрим Тинчурин театрының атказанган артисты Зөфәр Харисов әнә шулай ди. 2019 елда оешкан «Могҗиза» студиясенә бүген 13 бала йөри икән. Араларында Даун синдромы белән авыручы, начар сөйләшүче һәм аяк-кулларында кимчелеге булган ДЦП диагнозлы балалар бар.

– Без «Могҗиза» студиясендә балаларның мөмкинлекләреннән чыгып эш йөртәбез. Театр артисты Салават Хәбибуллин алар белән махсус күнегүләр ясый. Сәхнә хәрәкәтенә өйрәтә. Гөлназ Нәүмәтова сөйләм телен алып бара. Театр уйнарга теләгән сабыйларның хыялларын юкка чыгармас өчен, без бу студияне оештырып, аларга мөмкинлек бирдек. Әзме-күпме артист тормышын, театрны күрсәтәсебез килде. Без алар белән «Беренче театр», «Сүнгән йолдыз»-лар дигән спектакльләрне сәхнәләштердек. Шушы көннәрдә премьера була. «Миһербанлык» дигән спектакль күрсәтәчәкбез, – ди Зөфәр Харисов. – Алар белән эшләү үзебезгә дә рәхәт. Әмма язмышларын театр белән бәйләү әлегә чынга ашмаслык хыял гына булып кала. Бу – зур проблема. Әгәр монда йөргән балалар Казан мәдәният институтына кереп, аны тәмамлап, артист булып чыксалар да, алар өчен хөкүмәт тарафыннан махсус театр оештырырга кирәк булачак.

Казанда физик мөмкинлеге чикләнгән балалар өчен «Э-моция» инклюзив театр студиясе эшли. Аның җитәкчесе Инесса Клюкина белән дә сөйләштек.

– Башта без «Юность» мәдәният йортында театр түгәрәге ачтык. Ул әкренләп студиягә әйләнде. Бездә авырулар да, сау-сәламәт кешеләр дә эшли. Безнең театрда актерлык белеме булмаган кешеләр уйный. Безнең режиссерларыбыз да, җырга, сөйләмгә өйрәтүче педагогларыбыз, хореографыбыз да бар. Алар бушка эшли. Хәер инде без коммерциягә булмаган социаль оешма (НКО) төзедек. Төрле грантлар отып, без үз көнебезне үзебез күрәбез, – ди Инесса.

Инесса театрда уйнарга теләүче балаларга киңәшен дә бирде.

– Бик телиләр икән, безгә килсеннәр. Бездә 18 яшьтән өлкәнрәкләр уйнаса да, без аларны чакырып калабыз. Хәзерге вакытта коллективка кешеләр җыябыз. Тора-бара алар да үз студиясен ача ала. Әнә шулай итеп, хыялларны чынга ашырып була, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РАВИЛ САБЫР: «БӘЛКИ МИН АЧУ КИТЕРЕРГӘ ТЕЛИМДЕР?»

Миндә зурдан кубып язучы булам, дөньяга үземнән нindидер яңа сүз, идея, фәлсәфә җиткерәм дигән теләк-хыяллар юк. Равил САБЫР үзе хакында әнә шулай ди. Аның белән язучылар корылтае, булачак үзгәрешләр, каләм һәм премия хаклары турында сөйләштек.

Тимур Биктимеров

:: Ябык әдәби конкурсның роман номинациясендә җиңгәннән соң, сине язучы дип яза, әйтә башладылар. Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә узган бәйгедән соң үзең нindидер үзгәрешләр сизәсеңме? Язучы булуның нindидер өстенлекләре бармы?

– Дәрәҗәне үстереп җибәрә торган сүз инде ул – язучы. Зур сүз, җитди. Гомумән, нindидер бәйгедә катнашып, җиңүчеләр исемлегенә кергәч, йөзең телевидениедә күренгәч, исемең матбугатта еш телгә алынгач, үсендереп җибәрә, әлбәттә, ләкин икенче ягы да бар. Язучылар берлегендә җиңүчеләрне котладылар бит әле. Шунда Зөлфәт Хәким белән аралашып алдык. Ул, конкурс булса да язам, булмаса да язам, акча түләсәләр дә, түләмәсәләр дә язам, ди, язмыйча тора алмыйм, ди. Миндә исә зурдан кубып язучы булам, дөньяга үземнән нindидер яңа сүз, идея, фәлсәфә җиткерәм дигән теләк-хыяллар юк. Мин язмыйча да тора алам.

Романны да конкурста катнашырга теләүдән язмадым. Шартларын игълан иткәч тә катнашырга исәбем юк иде әле. Ләкин бик күп кешеләр, катнашасыңмы, ни язасың, дип сораштылар. Хикәя булса да язып җибәр, дип әйтүчеләр дә, повесть яз, ә бит син роман да яза аласың, дип әйтүчеләр дә булды. Шуннан, әллә язып караргамы, дип тә уйлый башладым. Аннан соң зур урында эшли торган бер кеше шалтыратты. Конкурс, аның дәрәҗәсе турында гәпләшеп алдык һәм ул да читтә калмаска киңәш итте. Аңа катнашмыйм дип әйтергә читенсендем. Шунда башланган да ташланган бер әсәрем искә төште, шуны эшләп бетерергә ният иттем.

Ният – бер нәрсә, әле бит тормышны, үз эшеңне дә алып барасы бар. Газета эше барыбер өйгә иярен кайта. Төннәрен утырып язган чаклар да була, язмасаң да барыбер башта йөри, темалар планлаштырасың, мәкаләгә баш исем уйлыйсың h.б., h.б. Кыскасы, эш кәефеннән иҗат дулкынына ничектер күчәргә кирәк иде. Аның өчен бертуктаусыз чабудан, газета конвейерыннан, образлы итеп әйтсәк, тегермән ташлары арасында әйләнүдән бер читкәрәк китеп, тынычланып, фикерләреңне, уйларыңны тәртипкә салу кирәк. Ә инде әсәргә кереп киткәч, персонажлар башыңда яши башлагач, вакыты да табыла, бар да җайлана икән. Әллә нинди сүзләр, үзара сөйләшкәндә гомер кулланмаган гыйбарәләр искә төшә. Фирдүс Гыймалтдиновка ике айда роман язган икән дип төрттерергә маташтылар бит әле. Кызып киткәч, ике айда да язып була икән романны. Агата Кристи, мәсәлән, бер айда да язган, Достоевскийның «Игрок» романын 28 көндә язганы билгеле. Ник дигәндә, һәвәсләнеп яза башлагач, дөньяңны онытасың, йокы да, эш тә, ял да икенче планга кала.

Мин башта повесть булыр дип тотынган идем. Ул языла да языла, гәрчә җәелмәскә тырышсам да. Тәмамлагач, повесть кына булмады бугай бу, дип уйга калдым. Ахыр чиктә әсәрнең жанрын күрсәтмәскә булдым. Детектив түгел, дип кенә искәрттем. Аны жюри роман номинациясенә кертергә булган.

Ә язучы дип эндәшүләренә мин инде күптән күнеккән. Журналларда хикәяләрем студент чакта ук чыга башлаган иде. Соңгы арада күбрәк драматург дип эндәштеләр, әлбәттә... Язучы дисәң, минем әле һаман чыккан китабым да юк бит. Минем кебек кенә күпләр яза ала, дип тә уйлый идем элегрәк. Баксаң, алай түгел икән. Ркаил Зәйдулла сөйләде, очраклы рәвештә генә моның кулына 20 ел элек басылган хикәям килеп кергән. Ни турында икән бу дип укый башлаган идем, кызыксынып, азагына кадәр укып чыктым, ди. 20 ел элек язылган хикәянең бүген дә укучыга кызыклы булуы – бик сирәк күренеш бит инде ул, сәләтеңне суга салма, дип киңәш бирде миңа Ркаил. Башкалар миндә язучы сәләте күргәч, чыннан да язучыдыр инде мин алайса *(көлә)*.

:: «Фәхрине үтереп ташладылар» – ул башта пьеса иде бугай.

– 2014 елда Камал театры чираттагы лаборатория оештырды. Анда режиссер белән драматурглар берләшеп, төркемтөркем эшләде. Шунда әлеге әсәрнең башын укыдым, 15ләп бите бар иде. Фикер алышу вакытында Фәрит Бикчәнтәев: «Жанры буенча бу – детектив, димәк, башта кемнедер үтерергә тиешләр, ахырда үтерүче кем икәне ачыкланырга тиеш. Син аны гадирәк яз, катлауландырма», – дигән иде. Андый детективлар муеннан бит инде, миңа алай язарга кызык булмады. Нindидер яңа форма табарга кирәк иде. Без режиссер Айрат Әбушаһманов белән бергә эшләдек. Айрат күптән түгел генә сыйныфташлары белән очрашуда булган икән, шуның хиссиятендә яши булып чыкты. Әбушаһманов, геройларның студент вакытында нindидер вакыйга булып, ул аларны бер-берсе белән бәйләргә тиеш, дигән идея әйтте. Бәлки алар нindидер вәгъдә бирешкәннәрдер, диде. Бу фикер дә башка кереп калды. Тагын бер нәрсә бар. Романда геройларның берсе Германиягә күченеп киткән. Илне ташлап чит җиргә китүнең мотивын аңларга кирәк иде миңа. Үзем чыгып киткән кеше түгел, димәк, шундый кеше белән аралашып, аның фикер сөрешен, мантыйгын аңларга кирәк. Хәзер бит интернет заманы, чит илдә яшәүче бер кеше белән аралашып алдык та, барысы да үз урынына утырды.

:: Романның исеме кызык, шул ук вакытта ачуны да китерә. Галимҗан Ибраһимов җөмләсеннән башка исем куеп булмадымыни?

– Дөнья әдәбиятында андый алым бар. Поэма-шигырь юларын алып куялар әсәр исеме итеп, халык мәкальләрен, бигрәк тә кинофильмнар исемнәрендә еш күрергә була моны. Ә Галимҗан Ибраһимовның «Фәхрине үтереп ташладылар» дигән җөмләсе күптән халык мәкале дәрәҗәсенә үсеп җиткән. Аны белмәгән татар бик сирәктер. Журфакта укыганда да, «Татарстан яшьләре»ндә эшләгәндә дә безне ул җөмлә белән бастылар да, изделәр дә инде. Сез укучыны язмагызның беренче сүзеннән үк каптырырга тиеш, дип өйрәттеләр. Кыскасы, бу – минем дә канга сеңгән җөмлә. Аны ничектер рациональ аңлатып та булмый, тик минем әнә шул җөмләне исем итеп куясым килде. Минем башта шушы баш исем туды, аннары әсәр языла башлады.

> Ачуны китерә димәктән, ә бәлки мин укучының ачуын чыгарырга теләгәнмендер?! Аннан килеп, классик әсәрләрнең кайсын гына алма, анда гадәттән тыш хәлләр, гадәттән тыш кешеләр тасвирлана. Шуңа күрә баш исемнең гадәттән тыш булуы ул әсәргә файдага гына. Баш исеме үк укучыны тынгысызлый икән, ул бик әйбәт.

:: Рөстәм Галиуллин аңа, популяр китап булачак, дигән бәя биргән иде. Шул ук вакытта, күпме язсагыз да, барыбер укымаячаклар, дигән фикер дә бар бит әле. Татар китабының ничә ел гомере калган, синеңчә?

– Татар китабының гомере озын әле, Аллаһ боерса. Конкурс бу фикерне куәтләде генә. Татар язучыларына аз гына игътибар күрсәтелгән иде, шундук мең ярым тирәсе әсәр язылды. Ярар, аның күбесе такмак дәрәҗәсендәге шигырь дә булсын ди, кайсылары чүп чиләгенә оча торган кульязмалар булсын ди. Арада бит нинди шәп әсәрләр бар! Әйтик, Зөлфәт Хәким сәламәтлеге өчен көрәшеп тә, шундый роман язган. Фирдүс Гыймалтдинов килеп чыкты. Мин 8 ел язмый торганнан соң утырып яздым. Повесть номинациясендә яңа исемнәр барлыкка килде. Болар бар да әдәбиятыбызга файда бит. Язучылар бар икән, укучысы да була. Һәр язучының азмы-күпме үз укучысы барыбер була.

> Зифа Кадырованы искә алыйк. Баштагы мәлләрдә әсәрләрен беркем чыгармады, үз акчасына китап бастырып, аны сатып, ул акчага икенче китабын бастырып, ахыр чиктә барыбер үз укучысын тапты. Һәм шактый күп аның укучылары. Хәтта бер язучы белән бер укучысы гына калса да, татар әдәбияты әле үлмәячәк.

:: Шул гомерне озайтабыз дип, әсәрне русчага тәрҗемә иттек ди. Ярдәме булачакмы?

– Ркаил Зәйдулла Язучылар берлегенә рәис булып сайланганда тәрҗемә мәсьәләсен күтәрде һәм беренче көннәреннән үк хәл итәргә дә алынды. Мәсәлән, миннән башта татар язучыларының төрекчә җыентыгына кертү өчен хикәя сорап алдылар. Бу җыентыкка кергән хикәяләрне Фатих Кутлу тәрҗемә итә икән. Ул башта җентекләп сайлый, аннары автор белән һәр сүзне, һәр җөмләне ачыклый, мәгънәсенә төшенә, үз эшен бик сыйфатлы башкара дип аңлыйм.

Күпмедер вакыт узгач, рус телендә дә җыентык әзерләүләрен белдереп, тагын шалтыраттылар. Шул ук хикәяне тәкъдим иттем. Шактый вакыт узгач, рус теленә тәрҗемәне укып карарга җибәрделәр. Беләсеңме, әсәрнең үз атмосферасы, мелодикасы була. Русча тәрҗемәдә менә

шулар югалган булып чыкты. Ул күбрәк механик тәрҗемәне хәтерләтә иде. Шуннан җавап язарга булдым. Мәсәлән, мин болай тәрҗемә итәр идем дип, сүзлекләр белән кичке алтыда эшләргә утырган идем, юк кына өч абзацны төнге бергә кадәр тәрҗемә иттем. Чөнки тәрҗемә ул – бик авыр эш. Ул сүзләрне тәрҗемә итү белән генә чикләнми, әсәрнең кәефен дә, атмосферасын да бирергә кирәк. Шул ук вакытта автор стиле дә сакланырга тиеш. Мин хат язып салгач, күпмедер вакыттан соң тагын бер вариант җибәрделәр. Бер генә мисалны китерәм. Анда бәләкәй малай, әбисенә үпкәләп, гөлбәч чаршавы артына поса. Аны, бәлкем, русчага тәрҗемә итеп тә булмый торгандыр инде, гөлбәчне «укрытие» дигәннәр, шулай да булсын ди. Ә малайның әбисе куенына сикерүен, тегесенең күтәреп алуын «нырнул в бабушкину постель» дип тәрҗемә иткәннәр. Әгәр ул тәрҗемәне миңа күрсәтмәгән булсалар, рус телле укучы, кем соң бу Равил Сабыр, ни язган соң бу, дип шаккатып укыр иде. Тәрҗемә юк язмадан шедевр ясарга яисә шедеврны юкка чыгарырга мөмкин. Тагын бер мисал. Шекспирның бер сонетын Маршак та, Пастернак та тәрҗемә иткән булган. Ике вариант та шәп, ләкин алар икесе ике әсәр буларак кабул ителә, гәрчә, әйткәнемчә, бер үк сонетның тәрҗемәсе булсалар да. Әлбәттә, башка халыклар татарларның да язучылары барын белеп торсалар, әйбәт. Ләкин беренче чиратта безне үзебезнең татар укырга тиеш.

:: Озакламый язучылар корылтае булачак. Уставка үзгәрешләр арасында иҗат әһелләрен хафага салганы да бар. Берлек рәисен сайлауны идарә хәл итәчәк дигән пункт ул. Бу үзгәреш берлекнең иреген кулкыныч тудырамы?

– «Демократия – идарә итүнең начар формасы, әмма кешелек аннан да яхшырагын уйлап тапмаган әле», – дигән Черчилль. Ләкин демократиянең дә төрле формалары бар. Кайдадыр парламент республикасы, кайдадыр президент республикасы, кайдадыр һаман корольләр бар, парламент монархиясе аларында. Кайбер илләрдә күп баскычлы сайлау системасы кулланышка кергән. Мин берлек уставына үзгәрешләр кертү турында сөйләгәндә ирекне кысу, авторитар режим урнашу кебек радикаль бәяләмәләр кулланмас идем. Беренчедән, идарә әгъзалары барыбер корылтайда сайлана. Әгәр язучыларның берлек рәисе итеп кемнедер күрәселәре килми икән, алар аны идарәгә дә сайламый гына. Сайлап куелган идарә әгъзалары үзләре арасыннан кемнедер сайлап куйган икән, димәк, аның берлек рәисе булырга тулы хакы бар. Икенчедән, Язучылар берлегенең иреге шулкадәр генә дисәң, бик үк дөрес түгел инде, ләкин ахыр чиктә барыбер язучылар берлеге рәисе республика хөкүмәтенә акча сорап барырга тиеш була. Хөкүмәт акчалата ярдәм итсә, берлек ниятләнгән планнарын тормышка ашыра ала, бирмәсә, эшли алмый. Мондa, миңа калса, балансны сакларга кирәк. Бер караганда, ул хөкүмәткә дә үз кеше булырга тиеш, икенче яктан, язучылар арасында да абруе зур булу кирәк. Бу нисбәттән Ркаил Зәйдулла – «самый кешесе», минем фикеремчә.

:: Апрель – Тукай премиясе кандидатлары өчен кызу ай. Күпләр нәкъ менә апрельдә матбугатта еш күренә, аннан соң югала. Кандидатлар арасында синең исем дә бар. Дүрт театрның эше арасында сезнеке кай ягы белән алдыра?

– Дөресен әйтик, кайчан да булса үз исемемне кандидатлар арасында күрермен дип күз алдына да китермәгән идем. Тормыш булгач, менә кандидат та булып куйдым.

Әгәр дә «Абага алмасы ачы була» дигән спектакль премия ала калса, аның өчен режиссер Фаил Ибраһимовның да, төп рольне башкарган Рафил Сәгъдуллинның да, минем дә, гомумән беркемнең дә йөзе кызармаячак. Чөнки бу – традицион жанрда, традицион ысуллар белән куелган чын безнеңчә, милли спектакль. Аның бөтен хикмәте һәм кыйммәте дә шунда: мөгез чыгармыйча гына яңа сүз әйтү, шуны тамашачыга җиткерү. Бу драма татар халкына 12 ел буе хезмәт итә инде. Аны елга берничә мәртәбә телевизордан да күрсәтәләр, шуңа да карамастан, халык һаман театрда уйналуын сорый. Күрәсең, ниндидер магниты бардыр. Аның сере турында Фаил абый белән шактый сөйләшеп утырган бар. Безнең фикеребезчә, сәхнәдәге ветеран бабайны күреп, һәркем үз бабасы язмышы хакында уйлана, аны терелткәндәй, йөрәк тибешен тойгандай була. Узган атнада ул спектакльне премия комиссиясе әгъзасы Илдар Ягъфәров килеп карады. Ул аны театр сәнгатенең алтын фондына керә торган спектакль дип бәяләде. Гомумән, бу драмага югары бәя бирүчеләр шактый. Икенчедән, бу спектакль чыгарылмаган булса да, режиссер Фаил Ибраһимовка барыбер Тукай премиясен бирергә кирәк булыр иде. Чөнки ул – шәһәр төзелгән вакытта театрны юк җирдән бар иткән кеше. Ул булмаса, бүген Чаллы театры булмас иде. Нульдән төзеп, 30 ел буена тартып барган, яшь артистларны җәлеп итеп, аларны үстергән, Чаллыда, гомумән, Татарстанда милли рух булдыруга, аны үстерүгә зур өлеш керткән кеше ул. Рафил Сәгъдуллинның бай һәм киңкырлы иҗаты турында да сәгатьләр буе сөйли алам.

:: Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Тукай премиясе күләмен 3 миллионга кадәр арттыруны үтенеп, Президентка хат язган. Әгәр премия күләме үсте ди, аның абруе артачакмы?

– Миңа калса, премиянең түгел, Татарстан җитәкчелегенең абруе артачак. Чөнки алар хакында, үзләренең иҗатчыларын хөрмәт итәләр, кадерлиләр икән, дигән фикер туачак. Премия Тукай исемендәге икән, аның күләме дә ил алдында читенсенми атарлык булырга тиештер. Әле мин 3 миллионны да аз дип саныйм. Бу суммага бүген машина алып буламы икән? Беркөнне эштә егетләр исәпләп чыгардылар, Сталин премиясе күләмен хәзерге акчага күчерсәң, 16 япон кроссоверы «Nissan X-Trail»ны сатып алырга булыр иде, әле тагын ярты машиналык акча кала. Әлбәттә, Сталин премиясе ул СССР күләмендәге бүләк булган, шул ук вакытта без дә бит, Тукай премиясе – иң зур бүләгебез, дибез. Менә шул ук ябык әдәби конкурсның дүрт номинациясендә җиңгән Лилия Гыйбадуллина бик шәп фикер әйтте: Муса Җәлил премиясе акчасына Казан үзәгендә бер бүлмәле фатир сатып алып булырга тиеш, диде. Ике куллап килешәм! Ә Тукай премиясе күләменә кимендә өч бүлмәле фатир алырлык булырга тиеш. Ничә сум тора икән хәзер андый фатирлар?

:: Мөмкинлек бирелсә, тормышыңда нәрсәне үзгәртер идең?

– Әлбәттә, булды үкенечләр дә. Яңадан яшәргә кирәк булса, нәкъ шулай ук итәр идем, дип әйтә алмыйм. Тик һәр үкенеч ул – тормыш тәҗрибәсе. Адәм баласы абына-абына, борынын каната-каната акыл җыя. Бер яһүд хатынына: «Сара Натановна, сез шундый акыллы!» – дигәннәр икән. Ул җавап биргән: «Мин акыллы түгел, тәҗрибәле. Акылым булса, бу кадәр бай тәҗрибә җыя алмас идем».

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы 25 март, 1 апрель саннарында

4

Кайсыдыр бер авыл янында идек, төгәл исемдә түгел.

Исемемне, яшемне хәтерләмәслек дәрәҗәдә сүзсез, кәефсез, ыргын, кызганыч хәлдә бара идем. Кичә иде, ахры, кәрванны икешәр-өчәр арбалык төркемнәргә бүленергә, арада утызар адым ара калдырырга куштым.

Көн тыныч һәм ояшлы. Арба тәгәрмәчләре тыкыр-тыкыр тәгәри... Ерактa, арада бер күренеп, зур канатларын җәеп очкан бөркетне күрдем, аклыма өметләрем килде...

Ерткыч кошның безгә якынлашуы, нәкъ өстебездә әйләнеп торуы бер дә әйбәт галәмәт түгел иде. Күп вакыт узмады, арттан инсан тавышына охшамаган, ук тиеп коега төшкән ана юлбарыс кебек ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелде:

– Козу, син генә түгел. Кәрванда синең кебек кайгылы тагын берничә ата бар...

Таш мәсьәләсе уртага чыккач, сөйләшү янә кузгалды. Берничә кеше юлга кузгалыр алдыннан төнлә эти-әниләренең кабер ташларын казып алганнар. Димәк, без генә түгел, шул кабер ташлары да Анадолуга юл тоталар. Бу хәлгә борчылыргамы, аптырыргамы, нишләргә белмәдем. Иң соңында Габдрахман әфәнде әйтте:

– Мин дә шулай эшләдем. Бу ташлар яңа йортыбызда күз алдыбызга куелмаса, безгә ул җир тиз генә ватан булмас. Ташсыз кеше – атасыз кешедер ки, кардәшләребез җирендә ятимчә каранып, читләрчә болганып йөрербез.

Суынган чәйләрне эчәргә теләмичә генә бетердек һәм бергә диярлек: «Әйвал-лаһ! Аллаһка тапшырдык!» – дидек.

Ташсыз кеше – атасыз кешеме? Габдрахман, бәлки, бик үк дөрес әйтмидер, әмма хаклы иде.

ГҮРБҮЗ АЗАК

МӘРЬЯМНЕҢ АТЛАРЫ

(РОМАННАН ӨЗЕК)

– Айдааааар!

Гүя җир тетрәде, кызыл кыялы таулар «Айдааааар!» дип иңрәде.

Мин дә шундый ук көчле тавыш белән артка борылып кычкырдым:

– Туктарга! Тукта!

Курку эчендә арбадан сикереп төштем. Ачы тавыш кабат яңгырады:

– Айдар, балам! Бөркетем! Айдарым!

Шул вакыт Мәрьямнең арттан җилдереп килгәнен күрдем.

– Гомәр абзый! Казибан апа акылын югалтты!

Калганын тыңлап тормадым, ашыгып, тавыш килгән якка киттем. Мин килгәндә берничә кеше һәм ире Козу арбадан төшкән хатынны тынычландырырга, юатырга тырышалар иде. Әмма Казибан беркемне ишетмәс, танымас хәлгә килгән. Тотып кала алмадылар, кулларыннан ычкынып, егыла-егыла читкә йөгерде. Артыннан карап калдык.

Уйга килмәгән, көтелмәгән хәлләр башланды, йөрәк түзсен.

Хатын йөгерә-йөгерә текә тауга менде. Кулларын күктә очкан бөркеткә сузып, баягы кебек ачыргаланып, елыйелый кычкырды:

– Айдарым! Айдарым!

Аннары хәлсезләнеп җиргә егылды. Арбалардан төшкән хатыннар аңа таба йөгерде. Йөрәге парчаланган, дөньяны югалткан ананы култыклап, арбасына алып барып урнаштырдылар. Аннары белдек: баласы Татар мәхәлләсе мәктәбендә үлгәннәр арасында булган. Ул көннән хәзергә кадәр ашамый-эчми, гел елауда барган... «Бөркетем» дип яратып үстергән баласы каберенә бер таш куя алмаган ана акылын шул ташсыз кабергә күмгән...

Ул арада төн кунарга туктaлдык. Ат арбаларын дүртпочмаклап тездек, уртага учак яктык, аш-су әзерләдек, самавыр кайнаттык. Атларны һәр төркемнән бер кеше утлатырга алып китте. Шулай утлап йөрсәләр, таңга кадәр тамаклары туяр. Төнлә арбалар уртасындагы мәйданчыкта кабызган учакка таллар, агач тамырлары атыштырып тордык, кара-каршы утырган хатыннар, ирләр шактый җылынды. Йоләре, күзләре яктырып китте. Казибанны онытып, аякка басарга җыенганда, уң ягымда утырган ире сөйләнде:

– Менә шулай, Гомәр абзый... Айдарның каберенә таш та куя алмадык. Куркам... Баламның кабере югалачак...

Атларны каракләрдан саклау өчен, учак янына, урталыкка керттек. Ул төн дәвамында җир астыннан ишетелгән төсле арган, елак тавыш акрын гына булса да кабатланып торды.

– Айдарым, Айдарым...

Ук белән атылган ана арыслан әле һаман кое төбендә иде...

Әй, бетмәс караңгылык! Гомәр хәзер ничек йокыга китәр?! Бу кәрван, бу таулар, йолдызлар?! Ничек йоклар?!

5

...Янә көн туганчы аякка калыктык. Арбаларны юлга тездек, тәгәрмәчләрен, күчәрләрен күздән кичердек. Атларның җәрәхәтле җирләренә дарулар сөрттек. Күзгә бер күренеп, бер юк булган кызны чакырдым:

– Мәрьям, янызыбга кил!

Калын киенгән, ак калфаклы кызый Актуганы белән бергә тиз генә килеп җитте.

– Абзый, ни булды?

Кичә кич җиңгәсе белән үлчәп кискән, уртасына кар төсендәге ак җеп белән «Аллаһ безнең белән» дип чигеп язган ал тукыманы селкеп күрсәттем.

– Менә байрагыбыз!

– Аңламадым, Гомәр абый...

– Бу – кәрван башында барачак байрак! Яшьләр белән ике метрлы тал табыгыз, шуңа бәйләгез. Менә баулары да әзер!

– Гомәр абзый, алда гел мин барачакмынмы?

– Әйе, син! Шуңа күрә байракны да син йөртәчәксең.

Кыз байракны кулына алды да чаптырып китте.

Мин борылып атларга кычкырдым:

– Кузгалдык!

Салкынча һавада арба тәгәрмәчләре, күчәрләре тыкырдады... Кояш сөңге буе югары күтәрелде. Уң ягыбызда – яңа гына күренә башлаган тауларда яфраклары коелып бетмәгән яшеллек шәйләнде. Сул ягыбызда – дала һәм еракларда кечкенә таулар. Баш очыбызда күгәрчен төсендәге болытлар арасыннан зәңгәр күк елмая.

Барып җитә алырбызмы?! Шулкадәр даланы, юлны, кичелмәс тауларны узып, бер тирән итеп җиңел сулыш ала, Госманлы җире чәчәкләренә, бөҗәкләренә, күгенә «Менә кавыштык!» дип әйтә алырбызмы? Кызык, ничә кеше, ничә ат, ничә арба барып җитәр?!

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА тәрҗемәсе

ВТ *Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана*

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Дания нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

БРИГАДА
СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ РАБОТ

Телефон: 89600509692
Реклама

КАРНИКА һәм КАРПАТКА токымлы бал кортлары семьясын сатам. 4 рамкалы, 2-3 кәрәзе – личинкалы, 1 кәрәзе – бал икмәге белән.
+7 96 55 99 88 67, +7 96 25 61 60 93
Пчелопакет Карника и Карпатка комплектация по 4 рамки 2-3 расплодом + 1 медаперговая
Реклама

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Кадер, ихтирам | Тарату | Африкадагы ил | Мөселман календаре буенча уныньчы ай | ... Куценко | Төс | ... юлны якын итеп | Композитор ... Даутов | Сибгат Хәким поэмасы | «Опель» модеге | Җырчы Георг ... | Борынгы Идел | Вахтанг ... | Сан | Авыз куышлыгының өске стенасы | ... Распутина | 10^{-9} | Дәүләт җыры | Агыйделнең сул кушылдыгы | Станислав ... (поляк фантасты) | Перу маркәзе | Албания акчасы | Яфраклы агач | ... акыл белән | Юл сандыгы | Итле шулпа өстенә чыккан май | Каклаган колбаса төре | Эренле шеш | Данлы исем, яхшы ат | Шәехзадә ... | Табигый минерал, мәгъдән | Актриса ... Хәйретдинова | ... Шагыйрьҗан

Раис Габдулла

25 март санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: хәрәсән, фанфара, Ион, фанза, дао, Лучко, Нарва, сарт, уа, саго, Мишка, Румба, Зуево, Шиһапов, кана, Ремарк, хаин. **Вертикаль буенча:** яшеру, Адамар, нар, гуаһ, Хафизов, Ом, акан, пари, рани, Амазонка, Фокус, Ува, стан, Чауш, Краков, Нуакшот.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Чыңгыз ханның Кытай башкаласы Пекинны яулап алуы ничәнче елга карый?
А) 1215;
Б) 1917;
В) 1556.

2 Гиппократ анты ул – ...
А) Габдулла Тукай әсәре;
Б) тынычлык турында килешү;
В) борынгы Грециядә, укып бетергәч, табиб вәгъдә итә торган этик йөкләмә.

3 Г. Камал исемендәге театр сезонын нинди әсәр белән башлап җибәрә?
А) «Сүнгән йолдызлар»;
Б) «Зәңгәр шәл»;
В) «Мөһаҗирләр».

4 Кәрим Тинчурин ничәнче елда туган?
А) 1938;
Б) 1812;
В) 1887.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) Б; 4) В.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 249

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булараk тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+